Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 43 (1459) 3 ноябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



6

Профессор Мөхетдин Корбангалиев утызынчы елларда Татарстанның сәламәтлек саклау министры булып торса да, аның кызы Мөкәррәмәне 8 елга хөкем итеп, Карлагка озаталар.

14-15

1990 елда Казанга килеп, Татарстанга үзе күтәрә алган кадәр мөстәкыйльлек вәгъдә итсә дә, үз сүзен үтәмәгән өчен соңыннан Ельциннан татар түбәтәен кире кайтарып бирүне таләп итәләр.

19

Муса Җәлил белән бергә Седльце һәм Демблин лагерьларын кичкән Ян Габдуллин 1943 елда әсирлектән качуга ирешә һәм, иң беренче булып, илгә яшерен оешма турында хәбәр алып кайта.

Орлык булыйм халык хәтеренә – Ә ул Татар диеп атала!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Төркия халкы Төркия җөмһүрияте төзелүнең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте.
- Россия Дәүләт Думасы 2024 елның 1 гыйнварыннан минималь хезмәт хакы күләмен 19 мең 242 сумга кадәр арттыру турында закон проектын беренче укылышта кабул итте.
- Казанның Татар китабы йортында «Татарча QR-код» дип аталган төрки-татар дәүләтләренең урта гасыр идарәчеләре мөһерләре күргәзмәсе ачылды.
- Казанда Бөтенроссия татар журналистлары форумы узды.
- Югары уку йорты студентлары өчен Татарстан Рәисе стипендиясе билгеләнде.
- Казан федераль университеты студенты Антоний Свердруп Россиядә уйлап табу үсешенә керткән өлеше өчен Альфред Нобель исемендәге медаль белән бүләкләнде.
- Казан табибы-балалар хирургы Дмитрий Осипов сабый кулын коткарып, Россия рекордлар китабына керде.
- Казанның 2 нче татар гимназиясендә яңа корпус төзү өчен республика казнасыннан акча бүлеп бирелде.
- Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов каләм ияләренең хезмәт хакын арттыру мәсьәләсен җитәкчеләр алдында көн саен күтәрүен белдерде.
- Түбән өлкәсенә эш сәфәре кысаларында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев «Искер» тарихи-мемориаль комплексы белән танышты.
- Татарстанда 826,9 тонна гошер сәдакасы җыелды һәм мохтаҗларга өләшенде.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

3 ноябрь – тәрҗемәче Люция Әнвәр кызы Гыйззәтуллинага 70 яшь (1953).

4 ноябрь – химик-органик, Социалистик Хезмәт Герое, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, СССРның Дәүләт һәм Ленин премияләре лауреаты Борис Александрович Арбузовның тууына 120 ел (1903-1991).

6 ноябрь – Татарстан Республикасы Конституциясе көне (1992 елда кабул ителде);

– шагыйрә, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Салисә Гәрәй кызы Гәрәевага 85 яшь (1938);

– Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры (элеккеге Татар дәүләт республика күчмә театры) оештырылуга 90 ел (1933).

СЫНАМЫШЛАР

● 4 ноябрьдән беренче кыраулар башлана, гадәттә, бу көнне коеп яңгыр ява ● 5 ноябрьдә ярма кар яки вак боз яву кышның 22 ноябрьдән башланачагын күрсәтә ● 8 ноябрьдә салкын һәм карлы булса, яз соң киләчәк, һәм киресенчә, бу көнне кар яуса, Пасхада да кар явачак ● Ноябрь кар өрә – галәмгә ашлык китерә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 53 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 02 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 09 минут.** Алдагы сигез көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **29 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **10 ноябрьдә 8 сәгать 40 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 9 ноябрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(5-13 ноябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедураларны үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигул ахир аеның 19 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Садри МАКСУДИ

ТАРИХИ МИРАС

(Дәүләт Думасында сөйләнгән нотык. – 13 март, 1912 ел)

Мөхтәрәм халык вәкилләре!

Гәрчә минем унычы буларак язылганлыгым бик яхшы хәтеремдә булса да, чыгыш ясаучыларны язу тәртибендә очраклы бер тәртипсезлек сәбәпле, чыгыш ясаучылар исемлегендә беренче булганмын. Шуның өчен сез иң әүвәл сөйләүчедән хөкүмәтнең Эчке эшләр министрлыгы тоткан сәясәтен гомуми рәвештә тәнкыйть итүне таләп итәргә хаклысыз. Ләкин мин сезнең өметегезне бушка җибәрергә мәҗбүрмен. Мин Эчке эшләр министрлыгының мөселман халкына бәйле эшләре хакында гына сөйләячәкмен. (Бу вакытта кайбер депутатлар арасында тавыш вә сөйләшүләр башланганлыктан, рәис аларга кисәтү ясый.)

Әфәнделәр! Без, мөселман фракциясенең вәкилләре, бу трибунадан мөселман халкы турысында сөйли башлагач, сезнең күбегез чынлыкта хөкүмәтнең, миллият вә дин аермасына карамый, һәммә-һәммә халыкка мөгамәләсе бертигез, ни өчен мөселманнар хакында булган сәясәтне генә аерым сөйләргә кирәк, дисез. Әфәнделәр, бу фикер бөтенләй үк дөрес түгел. Без гомуми Русия халкы күрә торган кысынкылыклардан башка, фәкать мөселманнарга гына махсус кысынкылыклар күрәбез. Әфәнделәр, һәр халыкның үзе өчен кыйммәтле вә мөкатдәс нәрсәләре була. Гадәттә, хөкүмәт кирәк кадәр реакция тарафдары булса да, халыкның бу мөкатдәс эшләренә катышмый, аларга тими. Бер халыкның ана теле, әдәбияты, мәктәбе вә башка нәрсәләре – ул халыкның мөкатдәс нәрсәләредер. Менә соңгы вакытларда чиновниклар безнең шушы мөкатдәс нәрсәләребезгә тыкшыналар. Безнең мәктәпләребезне, әдәбиятыбызны һәм безнең иң әүвәл дөнья вә галәм белән таныткан вә без кечкенә вакыттан ук анабыз сөйләшкән телне кыса башладылар.

Безнең фракция әгъзалары бу трибунага бик сирәк чыгалар. Фәкать эчтә әллә никадәр ризасызлык, кайгы җыелгач кына чыгалар. Шуның өчен без салкын кан белән генә сөйли алмыйбыз.

Әфәнделәр, хөкүмәтнең безнең хакта тоткан сәясәтенең сәбәпләрен һәм аның нәтиҗәләрен сөйләүдән элек мин фәкать бер ел эчендә генә чиновниклар безгә никадәр закон тәртипләренә каршы кысынкылыклар ясаганын санап чыгуны үземә бурыч дип беләм. Мин һәммәсен санамыйм. Фәкать зурракларын гына әйтеп үтәм. Югыйсә минем нәтиҗәләремне бушка хисапларлар...

Фәкать бер ел эчендә ошбу кешеләрдә тентү һәм арестлап ясалды. Москва институтында төрки телле мөгаллим Хәсән Сабрый Айвазовка әүвәл тентү ясап, соңыннан сөрделәр. Соңра Казан муллаларыннан Габдулла Апанаев һәм Галимҗан Галиевтә тентү ясалып, әллә никадәр язу вә китаплар конфисковать ителде. Вятка губернасы, Сарапул өязе, Бубый авылында мөдәррисләрдән Габдулла һәм Гобәйдулла Нигъмәтуллиннар һәм тугыз мөгаллим кулга алындылар. Алар шушы кешеләр:

Нәҗиб Думави, Мирзамозаффар Галиев, Габдулла Фәхри, Габделхак Ильясов, Шәриф Габсаттаров, Фатих Фәйзуллин, Фәхрелислам Рәшидов, Әхмәтфаиз Даутов. (Шәриф Габдесаттаров – рус теле мөгаллиме.)

Бу кешеләрдән 500 ләп китап конфискация ителгән.

Рәис:

– Кыскарак сөйләсәгез иде?

– Яхшы. Миңа рәис һәммә фактларны санап чыгарга рөхсәт итми. Андый фактлар миндә бер дәфтәр. Кыскасы, бер ел эчендә мәгълүмрәк мулла вә мөгаллимнәрдән бары 150 дән артыграк җирдә тентү ясалды, әллә ничә мәктәп, беркадәр мәтбага (типография) нәшере, мәгариф җәмгыятьләре ябылды. Арестлар хакында сөйләмим дә. Фәкать нәшере мәгариф оешмаларын гына күрсәтәм. Кукандта җирле инспекторның әмере белән 20 ләп мәктәп ябылып, мөгаллимнәре куылды. Бөгелмә өязе Арсай авылындагы мәктәп ябылды, мөгаллиме сөрелде. Уфа губернасы Минзәлә шәһәрендә «Сәгадәт» көтепханәсе ябылды. Казанда «Үрнәк» мәтбагасы ябылды. Варшауда бер мәктәп ябылды. Верхневодинск шәһәрендә мөгаллим чыгарылды. Петропавел мәдрәсәсе ябылып, имам Хәсән Понамарев кулга алынды. Ош шәһәрендә мөдәррис Мөхәммәтәмин укытудан тыелды. Бакчасарайда Гали Тарпиның китап кибете ябылды. Әлбәттә, иске мәктәп урынына яңа бина салырга рөхсәт ителмәде. Царицын шәһәрендә Ихсанов белән Янгалычев балалар укытудан тыелдылар. Казанда мәдрәсәи «Мөхәммәдия» мөдәррисләреннән өч кеше: Мостафин, Шәрәф һәм Зәбировлар мөдәррислектән тыелдылар. Хатыннар мәктәбендә мөгаллимә Нәфисә Казакова укытудан тыелды. Ташкентта Мөнәвәр карыйга мәдрәсә янында русский класс ачарга рөхсәт итмәделәр. Наманганда Хәсән Макаевны укытудан туктаттылар. Астрахань, Казан, Сембер вә башка шәһәрләрдәге җәмгыятьне ябарга сенат карар бирде. Казанда 17 нче мәчет янындагы мәктәп ябылды. Казан губернасында, бу да сәбәпсез администрация тәртибенчә, 20 мулла хезмәтләреннән чыгарылдылар. Рәис әфәнде кыскарак сөйләргә үтенгәнгә күрә мин артык санап тормыйм. Газеталар хакында ошбу сүзләрне әйтә алам: Баку шәһәрендә нәшер ителә торган көндәлек «Күнәш» газетасы туктатылды. Шул ук шәһәрдә «Һилал» һәм «Мәгълүмат» журналлары ябылдылар. Бер ел эчендә «Вакыт» газетасына 800 (сигез йөз) сумнан артыграк штраф салынды. Бакуда «Сада» һәм «Мәгълүмат»ка, казакъ газетасы «Айкап»ка штрафлар салынды.

Мин һәммә фактларны санап бетермим. Бары зурракларын гына әйтеп үтәм. Кыскасы, бер ел эчендә 150 ләп мөселманда тентү ясалган, 70 тән артык зур мәктәпләр ябылган. Иң зур газета вә журналлар туктатылган. Фәкать шушы бер ел эчендә шулкадәр муллаларны борчыганны, шулкадәр мәктәпләрне япканны күргәч, ихтыярсыз түбәндәге ике фикергә киләсең: яисә рус хөкүмәте безнең мәдәниятләшүебез һәм алга баруыбызны теләми, ничек булса да шуңа каршы тормакчы була, яисә мөселманнар арасында Русия дәүләтенә каршы бер хәрәкәт, бер фикер бар һәм гадәттән тыш чаралар белән шуңа каршы торырга кирәк дип ялгышыла. Минемчә, бу фикернең һәр икесе дөрес. Гомумән, хөкүмәт күптән бирле безнең мәдәниятләшүебезне басарга тырыша. Хөкүмәт Русия мөселманнарының тәрәккый итүен, алга баруын теләми. Ләкин безнең мәдәни хәрәкәтләребез хәзер бигрәк гакыл белән эшләнә. Чөнки безнең бу хәрәкәтләребезгә каршы тору өчен кылынган чаралар панисламизм бар дип уйлаганнардыр.

Хәзер уңнар һәм хөкүмәт мөселманнар арасында панисламизм дип атала торган куркынычлы бер хәрәкәт булганга күрә, без хәзер мөселманнарны кысу хакында каты чаралар күрәбез, диләр. «Мөселманнар арасында шундый куркынычлы бер хәрәкәт, хөкүмәткә каршы берләшкән бер фирка бармы?» дигән соальгә каршы алар: «Бар», без: «Юк», – дибез.

Әфәнделәр, соңгы вакытларда уң газеталар һәм аның язучылары панисламизмга каршы тору өчен төрле чаралар күрсәтәләр. Шул газеталардан һәм хөкүмәт чыганакларыннан моны ишетеп, без таныш муллаларыбызга, мөгаллимнәргә, хәттә кайбер байларга мөрәҗәгать итеп: «Панисламизм нәрсә һәм халык арасында шундый бер хәрәкәт бармы?» – дип сорадык. Алар бу соальгә каршы аптырап калудан башка бернәрсә әйтә алмадылар. Шуннан соң панисламизмның барлыгы һәм халык арасында таралганлыгы исбат кылынган хөкүмәт чыганакларына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Мин хөкүмәт документларының берсендә панисламизмның аңлатмасын шушылай таптым: «Бу – һәммә мөселманнарны мәдәният һәм сәнгать җәһәтеннән берләштерергә тырыша торган бер хәрәкәт». Ул документларда панисламизм дип атала торган бу хәрәкәтнең бигрәк тә Волга-Кама әтрафларында таралганлыгы бәян ителгән. Димәк, бездә панисламизм бар, дип гаепләү – Волга-Кама татарларын мөселманнарны мәдәни вә сәнгать җәһәтеннән берләштерергә тырышалар, дип гаепләү буладыр.

Әфәнделәр, мин белмим, мәдәни җәһәттән артта, административ ягыннан кысылган, икътисади җәһәттән ярлы булган 4-5 миллионлы Волга-Кама буендагы татарларның бөтен Җир йөзендәге мөселман халкын берләштерергә тырышулары мөмкинме? Бөтен мөселман халкын берләштерү ни дигән сүз? Бу – Филиппин мөселманнарын, Һиндстан мөселманнарын һәм Азия, Африка һәм башка җирдәге мөселманнарны берләштерү, дигән сүз. Мәдәният җәһәтеннән артта, икътисади җәһәттән ярлы булган 4-5 миллионлы Волга-Кама буендагы мөселманнарның Азия белән Африканы берләштерү шикелле шундый бер зур мәсьәлә белән шөгыльләнүләре мөмкинме соң? Бу эш Александр Македонский һәм Наполеон Бонапарт шикелле даһиларга да мөмкин булмаган мондый буш сүзгә ничек ышанырга кирәк? Аннан соң безне истикъляль (сепаратизм) ясарга тырыша торган халык дип тә гаеплиләр. Истикъляль ясау, минемчә, нәрсәдән булса аерылырга тырышу, дигән сүз.

Димәк, безне Русиядән аерырга тырышалар, димәкче булалар. Берничә минут кына башка фикерләрдән аерылып торып, зыялы адәмнәп булып уйлап карыйк. (Бу арада уңнардан: «Нәрсә дисез?» һәм аларга каршы рәиснең кисәтүләре ишетелә. Пуришкевич: «Сез әле үк мәдәниятле түгел дигән идегез ич», – дип кычкыра.

Миңа дәвам итәргә рөхсәт итсәгез иде. Идел буендагы икътисад вә мәдәният җәһәтеннән артта калган 4 миллион мөселманның 100 миллионлы рус эченә кысылган һәм 16 гасырда Русия кул астына калып, шул 4 гасыр эчендә тыныч һәм иттифак белән яшәгән мөселманнарның кинәттән Азия илә Африканы сәяси һәм мәдәният җәһәтеннән берләштерергә тырышулары мөмкинме соң? Әфәнделәр, мондый сүзләрне уйнап кына сөйләргә мөмкин, әмма чынлап әйтергә ярамый. Бигрәк тә шул уен сүз аркасында тыныч кына тора торган бер халыкны кыса башласалар? Мондый эш ул вакытта зарарлы бер ялгышу булгандыр.

Әфәнделәр, әгәр дә панисламизмның барлыгы хакындагы ялгыш фикерләр шул кысуларга сәбәп булмаса, мин тормышта һичбер булмаган хыялый панисламизм хакында сөйләп тә тормас идем. Соңгы елларда булган бу кысуларның һәммәсенең баш сәбәбе – панисламизм бар дип гаепләүдәдер.

Муса Бигиев кабере табылды

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин эш сәфәре вакытында Каһирәнең Әл-Карафа некрополендә – башкаланың көньяк-көнчыгышындагы мөселман зиратында булды. Алар бергә күренекле татар дин галиме Муса Бигиев каберенә истәлек билгесенең рәсми төстә ачылуы нисбәтеннән килде.

Бу мөһим вакыйга уңаеннан каберне Мисырның Король йорты лидеры, Мисыр һәм Суданның соңгы хедиве (оттоман җитәкчесе) оныгы, принц Аббас Хилми бәй, Мисыр Гарәп Республикасының туризм һәм борынгылык министрлыгының ислам һәм коптларның борынгылык идарәсе башлыгы, профессор Әбү Бәкер Әхмәт һәм Бәйсез Дәүләтләр берләшмәсе, чит илләрдә яшәүче ватандашлар эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлыкның Мисырдагы вәкиллеге башлыгы Марат Гатин зиярат кылды.

Муса Бигиевнең җирләнгән урыны моңа кадәр билгесез иде һәм Камил хәзрәт үтенече буенча чит илләрдә яшәүче ватандашлар эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлыкның Мисырдагы вәкиллеге һәм Мисырның туризм һәм борынгылык министрлыгы ярдәме белән табыла. Килешүләр нәтиҗәсендә Каһирә хакимиятләре катнашында мемориаль урында истәлек билгесе ачылды.

Мисыр Гарәп Республикасының туризм һәм борынгылык министрлыгында Мисырдагы ислам һәм коптларның борынгылык идарәсе башлыгы Әбү Бәкер Әхмәт Мөфтигә каберне эзләү, аны саклау һәм архив документларын өйрәнү буенча күрелгән чаралар турында сөйләде. Муса Бигиевка кагылышлы барлык документлар, аның турында замандашларының язмалары шулай ук очрашу вакытында Россия ягына – Камил хәзрәткә тапшырылды.

Муса Бигиевнең кабере Каһирәнең Әл-Карафа некрополендә, Король каберлеге территориясендә (Мисыр король династиясе Мөхәммәт Али каберлеге), принцесса Хадига (Хадиҗә) кабере янында урнашкан. Очрашуда катнашучылар биредә Муса Бигиев каберендә Истәлек билгесен ачу тантанасы үткәрде. Татарстан мөфтие Коръән укыды һәм күренекле татар-мөселман галиме рухына багышлап дога кылды. Камил хәзрәт билгеләп үткәнчә, табличка кую татар галименә олы хөрмәт күрсәтү билгесе булып тора, ә татар дини мирасы хезмәтләрен торгызу Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең санала.

Мисыр вәкиллеге Мөфтигә шәехләр истәлегенә һәм аларның хезмәтләренә игътибарлы, сакчыл мөнәсәбәттә булганы өчен рәхмәтләрен җиткерделәр.

Муса Ярулла (Муса Җаруллаһ) Бигиев 1874 нче елда туган, фәлсәфәче-дин галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе. 1896 нчы елдан ул Каһирәдәге Әл-Әзһар университетында, аннары Мәккә һәм Мәдинәдә белем ала. Муса Бигиев Һиндстанга килә, анда мөселман дин галимнәре белән аралаша, дини темаларга диспутта катнаша, 6 ай дәвамында Диюбент шәһәре ислам университетында, аннары Бомбейда укый. 1904 нче елда ул Россиягә кайта. 1905 нче елда журналистлык эшчәнлеген башлый, бернечә хезмәтен бастыра. Бар гомерен М.Бигиев исламның фундаменталь кыйммәтләрен торгызуга багышлый һәм алар нигезендә көнкүрешне җайга салу принцибына иярә. 1949 нчы елда Каһирәдә вафат була.

https://dumrt.ru

Шаян артист китабы

Талантлы кеше – бар яктан да талантлы, диләр. Хак сүзләр.

Күренекле сәхнә остасы, популяр җырчы, алып баручы Җәвит Шакировның Татарстан китап нәшриятында әле генә дөнья күргән «Моңлану» китабындагы шигырьләрен укыгач, халкыбызның талантларга бай гына түгел, андый шәхесләрнең киңкырлы булуына да инандым. Җәвит абый әйбәт шагыйрь дә икән. Күңелендәге иксез-чиксез моң җыр һәм нәфис сүз булып кына чыгып өлгерә алмый, ургып аккан тау елгасына тиң җан авазы – илаһи ташкын – шигырь булып та ярала.

Җәвит абый җырчы булгач, аның шигырьләре дә җырлап тора, тел һәм юмор остасы булу да үзен нык сиздерә.Үзе язганча, аның күңеле тыныч түгел. Ул туктаусыз уйлана, елмая-көлә, сагышка да бирелеп ала, сагына, борчыла, ярата... Әнкәйләрне олылау, туган якка, туган җиргә, үз халкына булган мәхәббәт, хатын-кызга хөрмәт һәм аерым бертөрле мөнәсәбәт, дуслар белән үз итеп һәм шаяртып сөйләшү, ара-тирә төрттереп алу – шигырьдән шигырьгә күчә, каләм иясенең бу хис-тойгылары тагын да яктырак булып күңел түренә үтеп керә. Үз-үзеңнән көлеп, җәмгыятьтәге кимчелекләрне ассызыклап күрсәтү дә хас аның иҗатына.

Заманында Татарстанның халык шагыйре Роберт абый Миңнуллинның «Шагыйрь генә булып калалмадым...» дигән саллы гына китабы дөнья күргән иде. Әйе, чыннан да, зур шәхесләр бер генә юнәлештә үсә алмый, тормыш дәрьясын киң колачлап йөзә. Бигрәк тә Башкортстан ягында туып, мәркәзебез Казанны язмышлары итеп сайлаган талант ияләре. Күп үрләр яулаган, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган Җәвит Шакировның да табигый таланты һәр өлкәдә дә уңышлы нәтиҗәгә китергән.

Ленар ШӘЕХ.

1 нче биттә – татар шагыйрәсе Салисә Гәрәевага 85 яшь.

Татарстанда мигрантлар саны арта

ТР Прокуратурасында Татарстан хокук саклау органнары җитәкчеләренең координацион киңәшмәсендә мигрантлар арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре турында фикер алыштылар, дип хәбәр итә күзәтчелек ведомствосының матбугат хезмәте.

Киңәшмәдә билгеләп үтелгәнчә, ел саен республика территориясенә, чит ил гражданнары керүе, беренче чиратта якын чит илләрдән, даими үсә.

Мәсәлән, 2021 елда чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган кешеләрне миграция исәбенә куюның 267 мең факты (+36,4 %) теркәлгән, 2022 елда – 337,4 мең (+26,3%), 2023 елның 9 аенда – 300 меңнән артык (+19,6 %). 2023 елның 1 октябренә ТР территориясендә әлеге категориядәге 117,6 мең кеше яши.

Кагыйдә буларак, аларның яшәү нигезләре булып хезмәт эшчәнлеге (54,1%), шәхси визит (17,7%), уку (14,3%), эшлекле сәфәр (6,9%), туризм (5%) тора. Чит ил гражданнарының шактый өлеше Казан (52,5 %), Яр Чаллы (14,5 %), Түбән Кама (13 %), Әлмәт (3 %) һәм Алабуга (2,6%) шәһәрләрендә тупланган.

2021–2023 еллар дәвамында республика территориясендә 19 меңнән артык мигрант Россия Федерациясе гражданлыгын алган.

Докладчылар билгеләп үткәнчә, мигрантларның хезмәт хокукларын яклауны тәэмин итү һәм аларның уңышлы социаль адаптациясе өчен шартлар тудыру аларның җинаятьчел мохиткә җәлеп ителүенә каршы торуның нәтиҗәле инструментларының берсе булып тора.

kazanfirst.ru

Россия гражданлыгыннан баш тартучылар саны билгеле

2023 ел башыннан алып 4,4 меңгә якын кеше Россия гражданлыгыннан баш тарткан. РФ Тышкы эшләр министрлыгының Консуллык департаменты директоры Алексей Климов РИА Новости агентлыгына биргән интервьюсында шулай дип белдерде.

«Россия гражданлыгын туктатуга килгәндә, 2023 елда 4,4 мең кеше аннан баш тарткан, бу узган елгы мәгълүматларга якын (2022 ел нәтиҗәләре буенча – 4,3 мең кеше)».

Биредә китерелгән саннар Россия гражданлыгыннан баш тартырга теләк белдерүчеләр саны акрын артуын дәлилли.

2023 елның беренче тугыз ае белән параллель рәвештә 15,1 мең кеше чит илдә Россия гражданлыгына кабул ителгән (нигездә, бу – катнаш гаиләләрдә туган балалар). Россиянең чит илләрдәге учреждениеләре шулай ук 12,5 мең баланың тугач та гражданлыгы булуын раслаган, диде Климов.

Шул рәвешле, әлеге күрсәткечләр үз балалары өчен ата-бабаларының Ватаны белән гражданлык элемтәсен саклап калырга теләүчеләр саны азаюын дәлилли. 2022 елда ул 23,5 мең һәм 13,6 мең кешегә тигез булган.

tatar-inform.tatar

Татарстанда үлем-китем очраклары кимегән

Росстат мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2023 елның гыйнвар – август айларында Татарстанда үлем-китем очраклары тулаем бер елга карата 6,1 процентка кимегән.

Республикада агымдагы елның сигез аенда 28 375 үлем очрагы теркәлгән, бу 2022 елның шул чоры белән чагыштырганда 1837гә азрак.

Идел буе федераль округының калган барлык төбәкләрендә дә шундый тренд күзәтелә. Үлем-китем очраклары Киров өлкәсендә аеруча нык (14,3 процентка, 13 164тән 11 287 очракка кадәр) кимегән.

Тулаем алганда, 2023 елның гыйнвар – август айларында Идел буе федераль округы территориясендә 247 494 (2022 елның шул чорында – 266 584) үлем очрагы теркәлгән. Бу узган елның шул чорыннан 7,2 процентка азрак дигән сүз.

Шул ук вакытта, ил күләмендә үлем-китем очраклары агымдагы елның сигез аенда 9,8 процентка кимегән (2023 елда – 1 169 719, 2022 елда – 1 297 327 очрак).

Тулаем алганда, үлем-китем очракларының азаюына бәйле тенденция июль ае белән чагыштырганда үзгәрмәгән. Элегрәк белгечләр үлүчеләрнең саны кимүне коронавирус пандемиясенең тәмамлануына бәйләп караган иде.

tatar-inform.tatar

Әлфия Авзалованың 90 еллыгына концерт

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында легендар җырчыбыз Әлфия Авзалованың 90 еллыгы уңаеннан зур концерт булды. Кичәдә үткәннәр белән киләчәк очрашты кебек, чөнки анда Ә.Авзалова исемендәге иҗат фестиваленең өченчесендә җиңеп чыккан лауреатлар да чыгыш ясады.

Опера театрында гадәттә купшы киенгән рәсми затларны күреп күнегелгән, бу юлы исә гап-гади җыр сөючеләр җыелган иде. Әлфия апабыз кебек гади абый-апаларның элеккеге матур җырларга сусавы күз карашларыннан сизелеп тора. Моңлы җыр бәйрәменә ашкынуларын күреп, кызык булып китә – яшь кешедә генә була торган күңел уйнаклау бу. Затлы җыр яшәлгән елларны сызып ташлап, гүя яшьлеккә, хыялый чакларга кайтара икән кешене. Шуңа күрә Бөтендөнья Татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев микрофон тотып залга чыккач һәм Әлфия Авзалова репертуарындагы җырлардан берәр куплет булса да җырлауны сорагач, тартынучы да, ялындыручы да булмады, җырлый белгәне дә, белмәгәне дә кулга микрофонны электерергә ашыкты. Җырлый белмәгән кеше буламыни ул? Тавышы булмаса да, кешенең күңеле җырлый ич. Менә шунда бүгенге заман өчен чит, ят була барган үтә нечкә, җылы хисләр бәреп чыкты. Һәр сүз, һәр нота белән ишетелде ул хисләр. Милли шура рәисе кабат сәхнәгә менгәндә туктатасы, тагын берсен генә җырлатчы, дип ялварасы килде. Әмма һәр нәрсәнең үз вакыты булган кебек, тантаналы бүләкләү минуты җитте. Әлфия апа мирасын саклаучы аның кызы Зөлфия Гомәр кызы Нигъмәтҗанова Васил әфәнде кулыннан «Бөтендөнья Татар конгрессы» халыкара Берлеге медален кабул итеп алды.

Тамаша залында яңгыраган моң бериш җырчылар, әйтик, Фердинанд Сәлахов, Айдар Галимов, Салават Фәтхетдинов, Римма Ибраһимова, Алмас Хөсәенов, Илгиз Мөхетдинов, Ришат Төхвәтуллин һ.б. җырлаганда яңарып-яңарып алды. Казан театр артистлары җырчының тормышыннан күренешләрне уйнап күрсәткәндә героиняны гәүдәләндерүче җырчы артисткабыз Алсу Фәйзуллина да тамашачы күңелен иркәләде. Авылдан ерак юл үтеп Казанга килгән җырчыбызны беренчеләрдән булып үз канаты астына алган җыр һәм бию ансамбленең бүгенге артистлары җырлаганда, биегәндә дә моңланды күңел. Гомумән, кичә бик кәттә әзерләнгән иде. М.Тәминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры да сәхнәгә милли киемнәр киеп чыкты, С.Гобәйдуллина исемендәге заманча музыка үзәгенең оркестры кичә буе уйнады, «Jive» төркеме катнашты.

Яшьрәк җырчылар чыккан саен исә моң каядыр эреп югалган сыман тоелды. Тавышлары да шәп, рәвешләре дә килешле, чит-ят аһәңнәр кушылгангадырмы, җырлары йөрәккә үтәрлек үк булмады.

Шулай да фестивальләр үткәрү кирәк. 2018 елдан беренче тапкыр узган Ә.Авзалова исемендәге фестивальгә 800 гариза килгән икән, җырчыларыбыз да, биючеләребез дә, нәфис сүз осталарыбыз да бар әле дигән сүз. Ул елны баш бүләкне Лилия Хөсәенова белән Илнар Миранов бүлешкән булса, 2021 елда 600 иҗат иясе катнашкан фестивальдә гран-при белән Алмас Хөсәенов бүләкләнде. Быел исә фестивальдә катнашырга 13 илдән 760 кеше теләк белдергән. Нәтиҗәдә, Татьяна Ефремова барысын да уздырган. Татьянаның исеме моңа кадәр сер булып сакланган һәм төп җиңүче буларак аны юбилей концертта гына игълан иттеләр. Т.Ефремова Яшел Үзәннән. «Керәшен чибәре – 2016» җиңүчесе. Күптән түгел исә ул Төркия, Үзбәкстан, Кыргызстан, Башкортстан, Әзәрбайҗан, Польша, Белоруссия, Молдова, Грузия, Бурятия, Болгария, Португалия, Испания, Аргентина җырчылары арасында беренчелекне яулап, Казахстанда узган Voice of Turan бәйгесеннән җиңү белән кайтты.

Чибәрләр дә, талантлылар да, әмма кайберләренең җырлавы залда «Ак чәчәкләр кебек кар ява» дип әкертен генә моңланган апаныкына тормый. Заман башка, җыр башка. Таныш та, таныш түгел дә шикелле...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Кариев театры «Алтын битлек» премиясенә номинант



Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры «Рөстәм маҗаралары» спектакле белән 5 номинациядә «Алтын битлек» Милли театр премиясенә дәгъва кыла:

1. «ДРАМА/КЕЧЕ ФОРМАДАГЫ СПЕКТАКЛЬ» номинациясе («Рөстәм маҗаралары»).
2. «ДРАМА/РЕЖИССЕР ЭШЕ» (Тимур Кулов).
3. «ДРАМА/ХАТЫН-КЫЗ РОЛЕ» (Татарстанның атказанган артисты Альбина Гайзуллина).
4. «ДРАМА/ИР-АТ РОЛЕ» (Булат Гатауллин).
5. «ДРАМА/УТ БУЕНЧА РӘССАМ» (Дмитрий Солопов).

Бу – Кариев театрының беренче мәртәбә «Алтын битлек» милли театр премиясе номинантлары исемлегенә керүе. Гадел Кутуй әсәре һәм аның улы Рөстәм Кутуй истәлекләре нигезендә куелган «Рөстәм маҗаралары»ның премьерасы узган елның декабрендә булды. Спектакль «Бердәм Россия» партиясенең «Кече Ватан мәдәнияте» федераль партия проекты грантына («Театрлар – балаларга» юнәлеше) куелды.

Шулай ук безнең «Гөлчәчәк» (режиссеры Булат Гатауллин) спектакле «Алтын битлек» премиясенең лонг-листына (эксперт советы фикере буенча, 2022-2023 нче елгы сезонда иң истә калырлык спектакльләр исемлегенә) керде. 2020 елда «Хикмәт әкиятләре» (режиссеры Сойжин Жамбалова) спектакле премиянең лонг-листына кергән иде.

Социаль ашханә ачылды

«Ярдәм-Помощь» гомуммилли хәйрия фонды үзенең игелекле эшләре, матур яңалыклары белән сокландырып тора. Әле кайчан гына «Ярдәм» мәчете биләмәсендә «ДАН» күпфункцияле спорт комплексы төзелеп сафка басуы сәламәт һәм физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә, шул исәптән коляскадагы инвалидларга спорт белән шөгыльләнү өчен барлык мөмкинлекләрне тудырган иде.

Шушы көннәрдә «Ярдәм-Помощь» гомуммилли хәйрия фонды тагын бер әһәмиятле социаль проект булдырды: аның үз биләмәсендә социаль ашханә ачылды. Биредә ялгыз өлкәннәр, мохтаҗлар, инвалидлар, күп балалы гаиләләр, аз керемлеләр, яшәү урыннары булмаган кешеләр кайнар ризык белән туклана. Социаль ашханәгә ризыкланырга керү өчен беркемнән дә документ таләп ителми. Шул ук вакытта «Ярдәм» хәйрия фонды алып бара торган «Тормыш юлы» акциясе дә дәвам итә, аның кысаларында мохтаҗлар, пенсиясе аз булган өлкәннәр, инвалидлар, йорт-җирләре булмаган кешеләрнең атнага биш тапкыр кайнар төшке аш белән туклануы оештырыла, шул ук вакытта ланч-бокслар таратыла. Социаль ашханә ачылган көнне үк, бу яңалыкны ишетеп, Казанның төрле районнарыннан йөзләгән мохтаҗ кеше Серов урамындагы 4 нче йорт янына җыелган иде инде. Киләчәктә дә биредә тукланып чыгарга теләүчеләр күп булыр дип уйланыла. Килүчеләрнең барысын да ашатачаклар. Туклану үзәгендә яшәү урыны булмаган кешеләргә кунып чыгу өчен уңайлы аерым бүлмә дә җиһазланган. Анда юыну урыны да бар. Ул урынҗир белән тулысынча тәэмин ителгән.

Киров һәм Мәскәү районнары имам-мөхтәсибе, «Ярдәм-Помощь» гомуммилли хәйрия фонды Советы рәисе, «Ярдәм» мәчете имам хатыйбы, хәйрияче Илдар хәзрәт Баязитов, мәрхәмәт акциясен шулай күркәм рәвештә дәвам итәргә булуларын, «Ярдәм» мәчете биләмәсен социаль оптимизм зонасы, дип йөртүләрен билгеләп үтте. Ул шулай ук «Социаль ашханә фонд алып бара торган шәфкатьлелек юнәлешен үстерүдәге тагын бер зур адымы», – дип искәртте.

Туклану үзәге модуль йортлар төзү юнәлешендә эшчәнлек алып баручы Нияз Гәрәевның шәхси тәкъдиме һәм химаячелек ярдәме белән булдырылган. Аларга эшне юктан башлап җибәрергә туры килгән. Әмма төзелешнең һәр этабында игелекле эшкә күп кенә кешеләр хәйрия ярдәме күрсәткән, төзелешне алып бару кыенлашкан чакта җилкәсен куйган. Берсе такта, агач материалы бирсә, икенчесе уңайлы, заманча юынгычлар, сантехника белән тәэмин иткән, берише акчалата булышкан. Алар арасында Татарстанда яшәмәгән кешеләр дә хәтсез булган. «Ярдәм итүчеләрнең үзләренә кирәкмичә аунап ятканны түгел, ә бәлки иң заманчалы китереп бирүләре аеруча күңелле булды», – диде Нияз Гәрәев.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

● Bloomberg язуынча, АКШның Россия уранынннан баш тарту омтылышларының барысы да уңышсызлыкка очраган. «Росатом» элеккечә үк уранны дөньяда иң күп житештерүче булып кала һәм Америкадагы 92 атом-төш реакторының чирегең, шулай ук Европа һәм Азиядәге дистәләрчә АЭС ны ягулык белән тәэмин итә. Күптән түгел исә АКШ Россиядән уран-235 сатып алуны 2,2 тапкыр арттырган һәм моның өчен рекордлы сумма – 696,5 миллион доллар түләгән.

● АКШның үзендә уран баету буенча предприятиеләрнең соңгысы инде 2013 елда ук ябылган, хәзер илдә атом-төш ягулыгы резервы нибары 18 айга җитәрлек калган. Дәүләт мәнфәгатьләре турында сүз барганда, АКШ берниди чикләүләргә игътибар итми шул, ә Европа илләре исә, Россиягә каршы санкцияләрне ничек яхшы үтәүләрен Америкага күрсәтер өчен, үз сәнәгать һәм икътисадларына зыян китерүен дәвам итә.

Гомеремнең шактый гына үтелгән иҗат сукмакларында Башкортстанның, Татарстанның абруйлы дәүләт җитәкчеләре, күренекле шәхесләре белән күзгә-күз очрашырга, мөселман дөньясын шаулаткан, хәтта чит илләрдә яшәгән якташлар белән дә элемтәгә керергә туры килде. Алар хакындагы язмаларым матбугатта, китапларымда урын алды. Ә менә бик иртә – 32 яшендә җитәкче «камытын кигән»нәр хакында әлегә кадәр язарга туры килмәгән иде. Бәян итәсе сүзем Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе ***Данис Шакиров*** *хакында. Баксаң, аның да нәсел тамырлары Башкортстанның Ярмәкәй төбәгеннән икән. 2017 елда Казанда үткәрелгән 1 нче Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр корылтае алдыннан очрашканда бу турыда ул үзе әйткән иде. Мондый форумда аның белән алдагы елда да очрашырга насыйп булды.*

Халкым дип тибә йөрәге

Бу чакта ул әлеге конгресс җитәкчесенең беренче урынбасары иде. Сүз артыннан сүз китте. Алдан элемтәгә кергәндә, бер уңайдан Казанда минем иҗат кичәмне үткәрү турында да тәкъдим булды. Мин инде үземчә әзерләнеп килдем. Ни дисәң дә, Башкортстанда туып, Татарстанда яшәгән данлыклы шәхесләр хакында ике китап бастырган автор булуымны да шәйләгәннәр икән. Әлеге тәкъдимне ул вакытта конгресс рәисе булган Ринат Закиров та хуплый. Алар чараны оештыруның шактый мәшәкатен үз өсләренә алды. Билгеле, әдәби геройларым җыелган сәхнәгә менеп мине тәбрикләделәр дә. Дистәләгән геройларым арасында Татарстанның халык шагыйре, өлкән дустым Рәдиф Гаташның катнашуы да зур мәртәбә иде. Шушы шатлыклы мизгелләрне кичерүемдә Данис Шакировның да роле зур булды. Халык шагыйре Әнгам Атнабай: «Кешегә бер җылы сүз, наз җитә», – дип юкка гына әйтмәгән. Кайчак бер җылы караш та, изгелек тә күңелләрне эретеп куя шул.

Тормышта шундый кешеләр була: беренче күрүдән үк ул синең күңелеңне яулап, ягымлы карашы, фәһемле сүзләре белән әсир итә. Аерылышкач та, күп еллар дәвамында аны оныта алмыйча «изаланасың». Данис Фәнис улы кылган изге гамәлләрне дә онытырлык түгел. Гәрчә миңа аның белән махсус әңгәмә корырга туры килмәде. Шулай да, аның кечкенә юбилее алдыннан бер кәлимә сүз әйтергә батырчылык иттем. Ул үзе шәһәр мөхитендә – Менделеевскида дөньяга килсә дә, күрәмсең, милли рух, туган телгә мәхәббәт әнисе Гүзәлнең күкрәк сөте белән иңдерелгәндер. Татар телле сыйныфта белем алуы да, җәмәгать эшләрендә актив катнашуы да, Казанда олимпиадаларда җиңүләр яулау да максатчанлыкның тәүге баскычлары булгандыр.

Соңрак, Казан (Идел буе) федераль университетының татар филологиясе һәм тарих факультетында белем ала ул. Бик яхшы уку белән беррәттән, Данис Шакиров, актив студент буларак, профбюро рәисе, төркем старостасы вазыйфаларын башкара, Бөтендөнья татар конгрессы оештырган чараларда катнаша, волонтёр да була. КДУны кызыл диплом белән тәмамлагач, ул аспирантурада белем ала. Диссертация яклап (җитәкчесе Әлфия Йосыпова), ул филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. 2011-2014 елларда ул – Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында әйдәп баручы референт. Соңрак аңа Татарстан районнарындагы җирле оешмалар белән эшләүче бүлекне ышанып тапшыралар. Бераздан ул Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгына төбәкара хезмәттәшлек секторы мөдире булып күчә.

2015 елда Д.Шакировны янә Бөтендөнья татар конгрессына, башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары итеп чакыралар. Бик җаваплы, масштаблы, катлаулы мәсьәләләрне эченә алган вазифа, әлбәттә. Дөньяда яшәгән татар халкының тормышындагы мөһим вакыйгалар белән хәбәрдар булу, төрле проектларны тормышка ашыру, милләттәшләребез оештырган чараларда, халыкара киңәшмәләрдә катнашу, чит төбәкләргә, төрле илләргә сәфәр кылу һ.б. мөһим чараларны оештыру мәсьәләре – һәммәсе игътибар үзәгендә булырга тиеш. Ни дисәң дә, җир йөзендә 7-8 миллион татар яшәвен, шулай ук Россиянең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә биш йөзләп җирле оешмалар эшләп килүен исәпкә алганда, бетәсе юк чараларда «кайнашырга» туры килә. Татарларның егерме биш процент чамасы гына Татарстанда, бер миллионнан артыгы күрше Башкортстанда яшәвен чамалаганда да, үткәрелгән чараларның иге-чиге юк. Аларның һәммәсен тормышка ашыру өчен дистәләгән төбәк, чит ил җитәкчелекләре белән сөйләшүләр, әзерлек эшләре алып барырга кирәк. Тагын да «яманы» – һәммәсенә вакыт, күпләгән халыкны, җирле үзидарәне, бигрәк тә мәдәният, мәгариф хезмәткәрләрен җәлеп итү, әлбәттә, матди чыгымнар да таләп ителә. Ансыз һич булмый. Һәр үткәрелгән чарада ихласлык, кунакчыллык, милли рух, гореф-гадәтләр һ.б. күркәм сыйфатлар чагылыш табарга тиештер, мөгаен. Бу җәһәттән, Конгресс төбәкләрдәге төрле проблемаларны хәл итәргә, инициаторларны, лидерларны хуплап, җирле хакимиятләр, активистлар белән уртак тел, матур юнәлеш табарга ярдәм итә.

Сөенечлесе шул: милләтебезнең йөзек кашы булган Бөтендөнья татар конгрессының башлангычлары республика җитәкчелеге тарафыннан һәрдаим хупланды. Аның эшчәнлеген вакытында күрә белеп, аңа һәрдаим ярдәм кулы сузган Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, аның алмашчысы булган Рөстәм Миңнеханов бу төбәкне бөтен дөньяга танытты. Алар үзләренең искиткеч изге гамәлләре белән, бөтен татар халкын әйдәп баручы җитәкчеләргә әверелеп, аеруча мөселман дөньясын шаулатты. Шуңа да чит мәмләкәтләрдә яшәгән милләттәшләребездә ихлас соклану, чиксез горурлык хисе уянадыр да инде. Кайда гына булса да, республика җитәкчесе милләттәшләребез белән очрашуны программага кертә. Аларның хәлләрен белешә, проблемалары белән кызыксына, ярдәм итү юлларын эзли.

Әйе, Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеге күпкырлы. Өстәп әйтсәк, мәсәлән, Россия татар сабантуен үткәрү генә дә бик зур, катлаулы, күләмле эш. Чорның гореф-гадәтләрен төгәл күз уңаеннан үткәреп, борынгы йолаларга тәңгәл китереп башкарырга, фольклор элементларын да урынлы кулланырга кирәк бит әле. Әйтик, быелгы Россия татар сабантуе Астраханьда шаулап-гөрләп үтсә, ә менә 2023 елның апрелендә тарихта беренче тапкыр Сабан туе чит илдә – Дубайда «Татарлар – без бергә» девизы астында югары дәрәҗәдә үтте. Анда Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов исеменнән Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе Д.Шакиров бирегә җыелучыларны котлады. Әле аңа шулай ук Омск өлкәсендә үзенчәлекле «Татар йорты»н ачу тантанасында, шулай ук төрле төбәкләрдә озак еллар үткәрелгән һәм башка бик күп милли чараларда да катнашырга туры килде. Конгресс шулай ук Курган өлкәсендәге Йолдыз татар авылында зур янгын чыккач, милләттәшләргә ярдәм йөзеннән 2 миллион сум акча, кием-салым, азык-төлек җыюны оештыруда да катнашты.

Билгеле, конгресс җитәкчелеге тугандаш, күрше Башкортстан Республикасы белән дә тыгыз элемтәдә яши. Ни дисәң дә, ул – татарларның күпләп яши торган төбәге бит әле. Татар конгрессының биредәге вәкиллеге җитәкчесе Альфред Дәүләтшинның сүзләренчә, Башкортстан җирлегендә дә санап бетергесез эшләр башкарыла. Аныклап әйткәндә, 2021 елның августында Данис Шакировның Мишкә районында каһарман якташыбыз Гази Заһитовка «Биш герой» мемориаль комплексында бюст ачу тантанасында катнашуы олы мәртәбә булды. Илгә танылган Башкортстан егетенә Казанда – Җиңү паркында Рейхстагка Кызыл Байракны беркетүче Гази Заһитов сыны гәүдәләндереп эшләнгән һәйкәлнең ачылуы да милләтпәрвәлекнең мәңге җуелмас билгесе булып хәтердә кала. 2021 елда Кушнаренко авылында легендар татар партизаны, «кара генерал» Даян Мурзин исемендәге күп профильле көллият мәйданы каршында аңа бюстын булдыруда, патриот-шагыйрь Фатих Кәримнең туган җире – Аит авылындагы (Бишбүләк районы) музеен яңадан төзекләндерүдә шактый матди ярдәм күрсәтүдә, Кыргыз-Миякәдә җәлилче Галләнур Бохаров исемендәге паркта агачлар утыртуда – һәммәсендә, шулай ук башка изге эшләрдә Конгресс үзенең якты эзләрен калдырды. Күп чараларның ачу тантанасында ТР Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиевның катнашуы шулай ук олы ихтирам билгесе булды.

Конгресс һәр төбәккә диярлек үзешчән халык коллективларына зур суммаларга милли костюмнар тектерә, заказ буенча гармуннар, китапханәләрне исә китаплар белән тәэмин итә, зур чараларны оештыруда матди ярдәм дә күрсәтә.

Әйе, конгрессның эшчәнлеген санап бетерерлек түгел. Бирелә үзен аямаганнар, халык күңеленә үтеп керә белгән ихлас хезмәткәрләр – милләтпәрвәрләр генә эшлидер, мөгаен. Гаиләне дә онытырга ярамый бит әле. Әйтик, яшь җитәкче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Данис Шакировның да гаиләсе бар. Кайчандыр, алар университетта укып, икесе дә төркем старостасы булган чорда танышкан Гөлнара һәм максатчан уллары Әмир белән бергә матур итеп, салмак кына тормыш сукмакларыннан атлыйлар...

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ,
журналистика ветераны.

Профессор Корбангалиев нәселе

● Автор М.Корбангалиевнең оныгы Ирек һәм онықчыгы Регина Сәйфи белән.

Мөхетдин Корбангалиев – педагог, профессор, татар теле буенча күпсанлы дәреслекләр авторы, әле сугышка хәтле үк Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасына нигез салучы һәм аны җитәкләүче шәхес.

● Мөхетдин Корбангалиев гаиләсе. Балалары Салих, Мөкәррәмә (алда) һәм Хәлимәнең сабый чаклары.

Аның улы Салих Корбангалиев – утызынчы елларда Татарстан Җөмһүриятенең сәламәтлек саклау комиссариаты (министрлыгы) җитәкчесе, Казан дәүләт медицина институтының беренче ректоры, медицина фәннәре докторы, аның исемен Казан урамнарының берсе йөртә. Мөхетдин Корбангалиевның кызы Хәлимә – биология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры. Ә менә Корбангалиевның олы кызы Мөкәррәмәнең язмышы алай сөенечле булмый, ул – Сталин лагерьлары газапларын үткән фаҗигале шәхес. Аның нәсел дәвамчылары белән Казанда очрашу насыйп булды.

Мөкәррәмә дә югары белемле табиб-рентгенолог, үпкә чирләре, туберкулез буенча зур белгеч була. Синтетик каучук заводында шартлау булгач, 1936 елның ахырында аның ире Шиһап Сәйфине, инженер буларак диверсиядә гаепләп кулга алалар һәм атып үтерәләр. Мөкәррәмәне исә 1938 елның 20 гыйнварында кулга алалар, 8 яшьлек Энҗе белән 6 яшьлек Ирек тә чиркәү төрмәсенә ябыла. Менә мин хәзер инде 92 яшькә җиткән Ирек Корбангалиев һәм Энҗенең кызы Регина Сәйфи белән очраштым. Бу нәселнең йөз еллык данлы һәм фаҗигале тарихы күз алдымнан үтте, аның тере шаһитлары каршымда утыра бит...

Узган гасырның утызынчы еллары – Мөхетдин Корбангалиевның иң күп һәм иң нәтиҗәле эшләгән чоры. Егерменче елларда ул, галим буларак, гарәп әлифбасында дәреслекләр, программалар, сүзлекләр әзерләгән булса, утызынчы елларда боларның барысын да латин хәрефләренә күчерергә кирәк була, кырыгынчы еллар башында исә тагын үзгәреш, инде кирилл әлифбасына күчәләр. Милли мәктәпләр буенча дәреслекләр әзерләүдә төп белгеч буларак, бөтен җаваплылык Мөхетдин Корбангалиев өстенә төшә, ә монда шәхси тормышында шундый зур фаҗига – кызының бөтен гаиләсе кулга алына, төрмәгә ябыла, торган квартираларын да тартып алалар. Инде җитмешкә җитеп килгән, сәламәтлеге шактый какшаган ата кеше кызы Мөкәррәмә һәм оныклары өчен соңгы көрәшенә ыргыла. Олы улы Салих, үз артыннан эзәрлекләүләр сизеп, 1935 елда Ленинградка киткән була һәм калган гомерен шунда яши.

Мөхетдин Корбангалиев үзе исән вакытта кызын төрмәдән чыгара алмый, әмма оныкларын НКВД тырнагыннан тартып ала, әниләре лагерьдан кайтканчы, алар бабаларында яши. Ә Мөкәррәмәне, халык дошманы дип, 8 елга хөкем итәләр, Казахстандагы Карлагка сөрәләр. Кызын төрмәдән чыгару өчен кая гына, кемгә генә язмый ата кеше! Татарстан Прокурорыннан башлап, Сталинга, Берияләргә хәтле хатлар яза, кайберләренә иректә калган ике баласы – Салих белән Хәлимә дә кул куя, алар ул вакытта икесе дә инде фәндә танылган кешеләр була. Бу хатлар ярдәм иткәндерме, юкмы – билгесез, әмма Мөкәррәмәне ярты срогыннан соң чыгаралар, тик әтисе аны күреп өлгерми, ул кызы төрмәдән кайтырга берничә көн калгач йөрәге ярылып үлә, бу хәл 1941 елның 3 июнендә була...

Әлбәттә, Мөкәррәмәгә Казанда яшәргә дә, эшләргә дә рөхсәт итмиләр, ул балаларын алып Минзәләгә китәргә мәҗбүр була, анда хастаханәгә эшкә урнаша. Сугыш вакытында ул үпкә чирле яралы солдатларны дәвалый, аларның соңыннан рәхмәт әйтеп язган хатлары гаилә архивында һаман саклана. Әмма рентгенолог булак эшләү, лагерь газаплары Мөкәррәмәнең сәламәтлеген нык какшаткан була, аның үзендә үпкә рагы башлана. Мөкәррәмә Мөхетдин кызы 1949 елны, 45 яшендә, Казан хастаханәсендә вафат була.

Мөкәррәмәнең балалары Энҗе белән Ирек ул чагында инде Казанда укый, кызы – медицина өлкәсен, улы географ белгечлеген сайлый. Аннан язмыш аларның икесен дә Әлмәт шәһәренә китерә, биредә алар гаилә кора, балалар үстерә, әмма соңыннан барыбер туган шәһәрләренә – Казанга әйләнеп кайта. Энҗе Шиһап кызы инде бу дөньяда юк, әмма ул әти-әнисенең архивын барлап, аларның тулысынча акланүын белеп китә, моның өчен үзе дә күп эшли. Хәзер аның бу изге эшен кызы Регина Сәйфи дәвам итә, гаилә архивы да анда саклана. Бу көннәрдә ул әнисенең теге елларда язган көндәлеген тапкан, хәзер шуларны эшкәртә. Танылган җырчы, педагог Регина Сәйфи, ире, музыкант, танылган пианист Марат Сиражетдинов белән ике ул үстергәннәр, Мөхетдин Корбангалиевның затлы нәселен дәвам итүчеләр бар, шөкер!

Мөхетдин Корбангалиевның кече кызы, университет профессоры Хәлимә Корбангалиева, галимә Флера Сафиуллина белән бергә, 2008 елда әтисе турында «Герой Труда Татарстана профессор М.Х. Курбангалиев» дип аталган китап чыгарган, ул да нәсел тарихын саклау буенча күп эш эшләгән. Ирек Корбангалиев исә заманында географ булып та, педагог булып та көч куйган, әмма гомер буе рәсем ясаган, сәнгатькә мәхәббәт аны Камал театрына рәссам-бутафор итеп китергән, ул шуннан лаеклы ялга чыккан. Моның өстенә әле ул Бауман урамында кешеләрнең портретларын ясаган. Ирек абый рәсемнәр ясаган альбомын миңа бүләк итәм, диде, ә мин аны бабасының туган авылына – Әгерҗе районының Биектау авылы мәдәният йортына тапшырырга ниятлим. Ул авылда Мөхетдин Корбангалиевны бик хөрмәт итәләр, олылыйлар, аның истәлегенә мәдәният йортында күргәзмә булдырылган, хәтер кичәсе уздырылган.

Без килгәндә, Ирек абый урын өстендә ята иде, егылып, оча сөяген имгәткән. Әмма зиһене бик ачык, хәтере яхшы, күңеле нечкә икән. Әнисе турында сорый башлагач, күзләренә яшь килде, берничә тапкыр тавышсыз гына, ирләрчә елап та алды. Аларны тентергә һәм кулга алырга төнлә киләләр. 6 яшьлек Ирекнең күңеленә иң уелып калганы - тентергә керүче хәрби аның кулындагы карандашын тартып ала, ә булачак рәссам өчен ул карандаш иң кадерле байлык була. Карандашын бирмәс өчен малай елый- елый тартыша, әмма барыбер алалар. Балаларны типкәләп, Казан уртасындагы чиркәүгә китереп ташлыйлар, алар анда, башка тоткын ятимнәр арасында, бабалары килеп алганчы яши...

Ирек Корбангалиевнең уллары – инде үзләре бабай, оныклары үсә. Бу нәселдә күпчелек медиклар һәм музыкантлар икән. Әмма шәһәрдә туып-үскән татар зыялыларының нәсел дәвамчылары да, гадәттә, үзләре кебек урыс телле була, аларга катнаш никахлар да ят нәрсә түгел. Миңа да татар теле белгече Мөхетдин Корбангалиевның нәсел дәвамчылары белән вакыт-вакыт русча аралашырга туры килде...

Ирек абыйга бабасының туган яклары Әгерҗе районыннан күчтәнәчкә бал, дини китаплар алып килгән идем. Шуларны биргәч, Ирек абыйның күзләренә тагын яшь килде, коры сөяккә калган кулларын күтәреп, дога кылды...

Быел Мөхетдин Корбангалиевның тууына 150 ел. Әмма Казанда аңа әзерлек эшләре күренми. Югыйсә, 1921 елда ук Татарстанның «Хезмәт батыры» исемен алган шәхес бит ул! Шул елны яшь республикада татар теле дәүләт теле дип игълан ителгәч, шуны тормышка ашыруның программасын эшләп биргән, урысларны татарчага өйрәтү өчен дәреслекләр язган галим! Элеккеге белгечләребез режим тарафыннан юк ителгәч, алардан калган йөкне үз җилкәләренә алган, милли мирасны саклап калуда искиткеч күп эшләр башкарган татар кешесе! Боларны хәтта теге елларда да яхшы аңлыйлар, аның үзенә кагылмыйлар, егылып үлгәнче эшләтәләр. Татнаркомпрос 1926 елның 9 декабрендә Мөхетдин Корбангалиевның фәнни-педагогик эшчәнлегенә 30 ел тулуны зурлап билгеләп үтә. Бу юбилей уңаеннан, Татарстанның Халык мәгариф комиссариаты Казан урамнарының берсенә Мөхетдин Корбангалиев исемен бирергә, дигән карар чыгара, әмма ул бирелмичә кала. 1994 елда фәнни җәмәгатьчелек галимнең тууына 120 еллыкны билгеләп уза, монда Мөхетдин Корбангалиев истәлегенә мемориаль такта куярга, шулай ук Казанның берәр татар мәктәбенә галимнең исемен бирергә, дигән тәкъдим була. Әмма боларның барысы да кәгазьдә генә кала – Казанда Мөхетдин Корбангалиев исемендәге урам да, мәктәп тә, истәлек тактасы да юк. Бары тик туган авылы Биектауда гына аны онытмыйлар, искә алалар. Шушы авыл мәктәбендә укыып, лаеклы ялга чыккан Эльза Сибгатова үзенең «Бөек Себер юлында Биектау» (Әгерҗе, 2021) исемле китабында якташы Мөхетдин Корбангалиевка тулы бер бүлек багышлаган, ул шушы темага фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясый, мәкаләләр яза. Әмма Мөхетдин Корбангалиев Әгерҗе кысаларына гына сыя торган шәхес түгел, аның юбилеен милләткүләм дәрәҗәдә билгеләп үтәргә кирәк. Ул моңа бик лаек!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.

* * *
Шау чәчәкле җәйге аланнарда
Күккә карап бармы ятканың?
Күзәткәнең бармы болытларның
Ак көймәләр кебек акканын?

Күренмим дә үлән арасында, –
Бер чәчәк мин, бөҗәк, кырмыска. –
Белә торып гомер кыскалыгын,
Чат ябышып ятам тормышка!

Ак болытлар булып еллар ага
(Мең гасырлар буе ага бит!).
Җир – борынгы, ләкин яңа туган
Һәр баласы өчен яңа бит.

И гүзәл җир, ата-анам җире!
Синдә тудым, сиңа китәрмен.
Тик үкенмим: бөтен хәтәрләрне
Халкым белән тигез күтәрдем.

Яшәп туймам!
Тормыш – койган бал ул:
Бер исереп йөрим, бер айныйм.
...Бу халәттән китсәм, шушы җирдә
Нәзек үлән булып уяныйм.

БОЛГАР ХАТЫННАРЫ

Зинданнарда болгар хатыннарын
Диннән яздырмакчы булганнар.
Рухларының таштай нык икәнен
Раслаганнар кабат болгарлар.

Әрхәрәйләр килгән тәре болгап:
– Иман диеп җансыз калмагыз...
Чукындырып исем кушарбыз да,
Иисус Христос булыр Аллагыз!

...Күнмәгәннәр горур әсирәләр –
Гомер киселәсен белгәннәр.
Иманга һәм Илгә тугры калып,
Башны ташка бәреп үлгәннәр!

Алар өчен Иман, Вөҗдан, Ватан
Бар нәрсәдән булган изгерәк.
Ил кызларын шундый тугрылыкка
Җырың белән өйрәт син, Йөрәк!

Илгә, Дингә, Телгә һәм Иделгә
Тугры калып Тарих кичкәндә,
Күп халыклар, телен, исмен җуеп,
Чит халыкка йомылып күчкәндә,

Искә алыйк, монастырьлар үтеп,
Чит туфракта табып гүрләрен,
Шәһит киткән болгар хатыннарын –
Нык Иманның бөек үрнәген!

ЧЕГӘН ЮРАВЫ

Әткәм учын карап, чегән әйткән:
– О, яшь егет! Юллар йөрерсең.
Чит-ят илләр, күп казенный өйләр
Һәм үлемнең үзен күрерсең.

Чәбәләнгән юллар арасында
Тоташ озын сызык – күрәмсең?
Мәхәббәттән, балалардан уңып,
Сиксән өчкә җитеп үләрсең.

Шулай булды. Ул багучы чегән
Алдамаган икән әткәмне:
Сиксән өчкә җитеп, гомер үтеп,
Үтәп китте чегән әйткәнне!

...Миңа чегән бәхет юрамады:
– О син, кызый! Учың кызыклы!.. –
Һәм аңлатып бирде иренмичә
Учымдагы һәрбер сызыкны:

– Мәхәббәтең сызыклары өзек –
Күп тапкырлар, димәк, янарсың,
Һәм берзаман идеал яр табуның
Хыял икәнлеген аңларсың.

Балаң – берәү, ирең – ул да берәү.
Казенный йорт. Юллар – казенный.
Байлык күрмим. Күрәм баш очында
Янып торган зәңгәр йолдызны.

Анысы, – диде, – миңа аңлашылмый,
Бәхетеңме әллә соң килгән?
Үлемеңне күрмим. Учларыңда
Сызыклар юк гомер өзелгән.

О, яшь кызый!
Синең учың кызык!
Серләр саклый анда һәр сызык.
Яшә, эзлә бәхетеңне җирдән,
Тик язмышны булмый һич узып.

...Шулай диде күрәзәче чегән
Яшьлегемнең чишмә башында.
...Мәшәкатьле, кызык минем гомер –
Чегән юраганы – каршымда.

И ГОМЕР!..

Кыска ла безнең гомерләр!
Гарешкә тартыла җан.
Юка ак кәфеннәр генә
Мирас аңа дөньядан.

Салисә ГӘРӘЕВА

Чыклар ярып иртән суга төшәм.
Сукмагыма карыйм әйләнеп:
Гүя үзем шушы сукмак белән
Туган җиргә торам бәйләнеп!

Нинди бөек без яшәгән заман!
Нинди татлы гомер елгасы!
...Табигатьнең газиз баласына
Ватаны тик үги булмасын!

АВЫЛ ОЧЫНДАГЫ ИСКЕ ӨЙ

Авыл очындагы иске өйдән
Бөдрә төтен чыга иртә-кич.
Димәк, өйдә әле тормыш бара,
Димәк, өйдә дөрләп яна мич...

Кышын карлар өйне күмеп китә,
Күренмәсен дипме утлары;
Авыл белән өйне тоташтыра
Карны казып сузган сукмагы.

Табигатьнең гади баласы мин – Бер каены, гөле, үләне...

Безне күпме ак хыяллар
Канатландырган иде.
Нәселебезне балаларда
Кабатландырган иде!

Мәңге яшәр өмет белән
Дөньяга килгән идек:
Тегесен алай, монсын болай
Итәм дип йөргән идек.

И татлы гомер чишмәсе!
Суың эчеп канмадым.
Фани икән бу дөньялар –
Бары шуны аңладым.

ХӘТЕР КӨНЕ

Хәтер көне хәтәр хәлебезне
Онытмаска өнди бакыйга.
Азатлыкка дәшкән шигар булып
Җанга сеңгән шушы вакыйга.

Ничә гасыр канлы яра булып
Сулыга ул йөрәк түрендә;
Ничә буын аша якты өмет
Тамырларга безнең үрелгән!

«Азатлык!» – дип иңләп урамнарны,
Шашкын агым йодрык чөйгәндә,
Сөембикә манарасы безгә
Иңрәп-сыктап башын игәндә,

Күзләрдәге яшьтән оялмыйбыз
Без ул көнне; ул яшь – мәңгелек!
Догаларда, ханбикәле Казан,
Искә алабыз сине иң элек.

Күз яшенә үрелеп Өмет туа –
Ирек килер Татар иленә!
Хәтер көне «Ирек» сүзе белән
Бергә кергән татар теленә!

ДОГА

Кеше тупсасына илтмә мине,
Баш идермә, кулым суздырма!
Һәм кайгылы кеше тирәсеннән
Гамьсез караш белән уздырма!

Кыюлык бир миңа кабихләрнең
Чыраена бәреп әйтергә!
Көнчеләрнең зәһәреннән сакла, –
Син утыртма мине иң түргә.

Ни кичерсә гавам, миңа да шул –
Артыгын да бирмә, кимен дә!
Чит җирләрдә мине түбәнсетмә
Һәм килмешәк итмә илемдә!

Ташлый күрмә кеше кулларына,
Мескен итмә, алма зиһенне!
Җиңел хаста, тиз үлемнән китеп,
Яд итсәмче синең исемне!

Көч бир миңа, алтын сабырлык бир!
Аера күрмә мине Ватаннан!
...Орлык булыйм халкым хәтеренә –
Ә ул Татар диеп аталган!

* * *
Кызыл миләш
Йомарлаган көз килә.
Бәхет соңлый,
Кайгы-хәсрәт
Тиз килә.
Берәү – бөкре,
Берәү
Горур, төз килә!
Әмма арттан...
Син калдырган
Эз килә!

Гел төз булып
Яшәү иде хыялым.
Йөрим, яшем
Күрерләр дип
Оялып...

* * *
Табигатьнең гади баласы мин –
Бер каены, гөле, үләне.
Чәчләремне тарап, таң җилләре
Шул турыда хәбәр сөйләде!

Ялан кырда үскән чәчәк кебек,
Кояш нурын эчәм көнозын.
Чылтыравын тыңлыйм чишмәләрнең,
Биек тауга менәм ялгызым.

Үткән елгы шиңгән яфракларны
Юри генә ачып карачы:
Яфрак асты саен гөҗләп торган
Серле, ят бер тормыш табарсың!

Күзем алмыйм яшел үләннәрдән,
Кояш назлап торган чәчкәдән:
Таҗларына бал кортының җиңел
Аягыннан ширбәт чәчрәгән!

Җәен аңа терәлеп үк ята
Арыш кыры, җилдә чайкалып.
Басуларга уза авылдашлар,
Уңган игеннәргә таң калып.

Көзен яфрак оча, яңгыр ява, –
Тәрәзләрен юа карт өйнең.
Ә морҗасы күккә төтен суза,
Бу тормышның саклап тәртибен.

Тыныч өй бу. Олы картлар йорты.
Сугыш ятимнәре алар да.
Җиде солдат, чыгып бу тупсадан,
Ятып калган әллә кайларда.

Сизгер авыл өйгә колак сала,
Хәл белергә килә иртә-кич.
...Авыл очындагы иске өйдән
Бөдрә төтен чыга – яна мич.

КЫЗЫМ

Киң дөньяга очты минем кызым –
Тургай очкан кебек биеккә!
Тыя алмадым:
– Гел берүзем калам,
ялгыз калам инде! – диеп тә...

Акчарлакны диңгез тарткан кебек,
ерак илләр тартты кызымны.
Самолеты җирдән аерылгач,
сулыгып-сулыгып йөрәк сызылды.

Очты кошым!
Давыл очрамасын,
ныгыганчы канат төпләре.
...Чәчәк булып шытсын йөрәгендә
сабый чакта имгән сөтләре!

РЕДАКЦИЯДӘН. Танылган шагыйрә, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, озак еллар «Мәдәни җомга» газетасы редакциясендә хезмәт куйган Салисә Гәрәевага шушы көннәрдә 85 яшь тула. Без каләмдәшебезне олуг гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык, имин-тыныч гомер, җан тынычлыгы белән яшәвен теләп калабыз.

Кулыма немецларның тагын бер архивы килеп керде. Анда сугышның беренче көннәрендәге Брест крепосте фотолары тупланган. Нәкъ менә шундый кадрлар ул фаҗигале көннәрне бик ачык итеп күз алдына китереп бастырырга булыша да инде.

Икенче бөтендөнья сугышының 1941 елның 22 июнендә түгел, 1939 елның 1 сентябрендә үк һәм шулай ук Брест крепостеннан башлануы мәгълүм. Аерма шунда гына: ул вакытка Польшаның күп өлеше инде яуланган була. Беренче фотода – крепостьның Төньяк-Көнбатыш капкасы. Немецлар Брестка якынлашкач, аны саклаучы поляклар бу капка каршына «Рено» фирмасы танкларыннан баррикада корган. Әмма озакка чыдамаганнар, һәм бу фото инде капканы саклаган баррикада җимерелгәч төшерелгән.

Ә бу фото капканы икенче ракурстан күрсәтә. Биредә крепостьны урап алган канал аша салынган күпер шәйләнә – соңрак, Брестны инде безнекеләр саклаганда, анда оборона җитәкчеләреннән берсе капитан Шабловский батырларча һәлак булачак.

Брест крепосте 1941 елда

(Немецлар төшергән фотолар)

Бу фотода каршы як ярдагы крепость казармалары бик ачык күренә. Әйләнә-тирә утлы өермәдән дер селкенсә дә, Брест әле нык тора.

Җимерелгән Тересполь капкасы, немецлар крепостька иң башта шуннан керә. Соңрак бу капка аша Гитлер белән Муссолини дә узачак, әмма әлегә аның артында сугыш бара. 1941 елның июнь таңында лейтенант Наганов немецларны сугышчылары белән нәкъ менә шунда каршылый һәм шул көнне үк һәлак була. Аның һәм тагын 14 сугышчысының сөякләре манара яныннан әле 1949 елда гына табылачак...

Икенче як ярдан тагын бер фото. Немец курыкмыйча басып тора, димәк, крепость эчендәге сугышлар инде ахырына якынлаша. Беренче көннәрдә төшерелгән фотоларда фашистлар болай басып торырга курка әле...

Ә бу фото башка позициядән төшерелгән. Биредә крепость символларыннан берсе – Холм капкасы яхшы күренә.

Без Брест фотоларының күбесенчә сугыш башында төшерелгән-нәрен күреп күнеккән. Немецлар архивыннан алынган бу фотоларда исә крепостьның безнең гаскәрләр тарафыннан азат ителгән чоры сурәтләнгән.

Бу фотода 1944 елда Брестта сугышның иң кызган мәле мәңгеләштерелгән. 37 миллиметрлы тупны артиллеристлар ут яңгыры астында күчерә. Брестта эссе, әмма безнекеләр бер адым да артка чигенми.

«Викинг» СС танк дивизиясе Брест янында. Танкларны безнең авиациядән урманга яшергәннәр, алгы планда – атаклы «Пантера». Өч елда немецлар Брестны һичкем яулый алмаслык крепостька әйләндергән, аны фашистларның иң яхшы көчләре саклаган.

Брест крепосте 1944 елда

Сирәк очрый торган кадр. Брест крепосте безнең гаскәрләр тарафыннан немецлардан азат ителгән көндә.

Шул ук көндә башка ракурстан төшерелгән фото.

Лейтенант Неустроев хатирәләреннән: «Брестны һәм Брест крепостен штурмлауны мин гомерем буена оныта алмадым. Бу бик кызу һәм онытылмаслык көннәр булды... Шәһәргә кергәч, без аның урынында көлгә калган хәрабәләргә генә тап булдык. Йортлар урынында сураеп торган каралып беткән торбалар гүя гитлерчыларның гаять зур каберлегендәге тәреләр иде. Урамнарда җимерелеп беткән, янып эштән чыккан танк, артиллерия, миномет калдыклары тулып ята...»



Ә болары – Брестта җирләнгән фашистлар. Беренче булып крепостька һөҗүм иткән атаклы 45 нче дивизия нигезендә Австрия солдатларыннан тупланган була.

Андрей Журавлев. «Дзен» челтәреннән.
Алсу Зәйдуллина тәрҗемәсе.

ТЕЛӘКӘЙ ЧИШМӘСЕ

(Дәвамы. Башы 42 нче санда).

– Монысы ни дигән сүз тагын? Баярлар хөкүмәте Әләкси патшаның кырык-илле санә элек олуг фәрман белән беркеткән безнең кануни биләмәләребезне чиркәүләргә саткан булып акча сугамыни? Әләкси патша безгә биргән фәрманнарга борын аслары да кипмәгән ике малай аай иткән буламы? Уң кул ни кылганны сулы белми, ниткән уен соң бу? – дип, инде артык түзеп тора алмыйча, Теләкәй морза да үз сүзен кистереп әйтте.

Аны шундук башка старшиналар да эләктереп алды.

– Мөселманнар җиренә китереп, чиркәү илә монастырлар салырга, безне яңа кирмәннәр илә уратып алырга җыенасызмы әллә?

– Мөселманны талап, һаман да шул нәсара (татарлар христиан дине вәкилләрен элек шулай атаган) атакайларын баету гына бит бу!

– Тәхеткә яңа падишаһлар менде дигәчтен дә, алар үз аталары язып калдырган фәрманнарны, аның антын аяк астына салып таптый икән!

– Бүгенге падишаһларның ошбу гамәле мөселман халкына бирелгән биләмәләр хисабына гоҗ баярлар кесәсен генә баету була лабаса! Кайсы яклап борып карасаң да, бу бит безне, мөселманны талау!..

Воевода ярдәмчесе Молоствов старшиналарның дәһшәт тулы йөзен, йодрык болгауларын күреп алуга ук өшәнеп калган иде, куркуын сиздермәс өчен үз янындарак басып торган бер офицер белән ни турындадыр пышылдашкан булды. Аннары Уфа каласы ягына борылды, көмеш таягын югары күтәреп кемгәдер хәбәр салды, берникадәр мизгелдән соң ук Бәрсуан елгасы ярында бер йөз чамасы укчы пәйда булды. Аларның кулында утчагыр мылтыклар шәйләүгә, янә Теләкәй морза корычтай аваз салды.

– Без ваевуда Каркадин чакырган җыенга коралларсыз килдек, иллә мәгәр ялчы Молоствов ише баярны гына бөгәрлек егәребез бардыр.

Теләкәй икенче мизгелдә үк сикереп кузгалды да, бер кулы белән Молоствовны үзенең кочагына сосып алды, аннары итек кунычыннан ялтырап торган хәнҗәр тартып чыгарды һәм аны боярның бугазына илтеп терәде.

– Сак көчекләреңә кире чигенергә әмер бир, югыйсә иң әүвәл үзеңне суячакмын!

– Укчылар, чигенегез, чиген! Ялгыш ут ачмагыз! Старшиналар коралсыз килгән булган...

Ике-өч минуттан соң Молоствов көймәле арбасына кереп утырды да, ике пар ат җигелгән олы олау Уфа каласы ягына чабып китеп барды. Теләкәй морза әүвәл ым кагып кына үз янына Сәгыйт хәзрәтне чакырып алды да, башка старшиналарның һәммәсенә ишетелерлек итеп соңгы сүзен әйтте.

– Баярларның этлегенә барчагыз да шаһит булдыгыз. Без – коралсыз килгән халык, заяга кан түкмәс өчен бүген таралабыз. Ләкин тиз арада кара тунга төренгән, җирәк сакаллы атакайлар килеп җитми калмас, шул чагында морзалар да үз авазын салыр. Моннан ары Казый мәчете янында түгел, шаукымлырак җирдә тупланырбыз...

* * *

Теләкәй морза су өстенә карап үз йөзен күргәндәй белеп торган икән. Шәбез буендагы утарына кайтып, атна-ун көн чамасы да вакыт узмагандыр, Чулман ярындагы Сарапул ягыннан хәбәр килеп җитте.

– Пермь каласыннан ун баркаска утырган укчылар вә поплар килеп төште. Аларның бер кыйсеме Зыязетдин морза биләмәсендәге җирләрне казып баганалар утырта башлады, анда ирләр монастыре төзеләчәк икән. Калган икенче зур нөгәр Ижау янәшәсендәге Пәрәү бистәсенә таба төбәп китте, алары Яуш морза биләмәсендә хатыннар монастыре төзергә ният итә икән...

Янә бер атнадан тагын яңа хәбәр:

– Пәнҗәр авылында, Талби морза биләмәсенең уртасында агач чиркәү төзи башлаганнар...

Теләкәй морза утардагы зур йорт эчендә аранга ябылган айгыр шикелле әрле-бирле йөренә, кайчагында ике як чигәсен кысып, сындай катып кала. Ни эшләргә, нинди генә гамәл кылырга соң? Ул – Агыйдел буендагы иң зур җирбиләүче. Биләмәсенең мәйданы илле мең дисәтинә булып исәпләнә. Бер өлеше атасы Улакайдан ук мирас булып калды, аңа өстәп, әллә никадәр җирләрне туснаклардан, өлешенә тигән яланнарны да эшкәртмичә яткан эт борчасыдай ялкау кавемдәшләреннән сатып алды. Шул биләмәләрендә бүген гомумсаны ун мең башка тулган елкы көтүләре утлап йөри. Аның байлыгыннан йөзәрләгән старшина һәм сәүдәгәрләр көнләшә. Ләкин, ләкин нәкъ менә шулар Теләкәй морзадан иң беренче итеп сүз көтә бит. Чөнки иң саллы, иң гаярь үгез кузгалса гына, көтүдәге сыер, сарык-бәрән, инеш суына егылып төшкән йомычка шикелле, аның давылына сосылып иярәчәк. Әгәр инде син дә олы башың белән кузгалмыйсың икән, ярлы-ябагайлар, яртылаш җиргә сеңгән йорт аламасының түбәсе тишек булмаганга шөкрәна кылып утыручы вактөяк куркак җаннар да таяк күрсәтүгә кача торган эт өеренә иярәчәк түгел. Димәк, син әйдәүче, син әләмче булсаң, хуш, меңләгән елкы көтүләре, хуш, буйсынуны белмәс газиз башым!..

* * *

Менә шулай бәргәләнгән көннәрнең берсендә Теләкәй утарына Агыйдел елгасы ярында эләктергән бер урыс качагын тотып китерделәр. Теләкәй аңа текәлде дә артына ава язды. Федор! Кырым сәфәрендә Теләкәй котолгысыз үлемнән йолып калган мескен укчы Федор!

Дөрес, ул хәзер инде печән чүбе, токмач калдыгы, балчык белән аралашкан сакал-мыекларга баткан. Теткәләнеп беткән киемнәренә дә, ябыгудан кибеп каткан йөзенә дә кызганмыйча гына карарлык та түгел. Күзләре дә тоз сипкәндәй тоныкланган сыман. Ләкин ул күзләрдә барыбер эчтән кабынган бер очкынны чамаларга була. Кием сәләмәләре арасыннан күгәреп беткән тәне, алардагы яра эзләре ачык күренеп торса да, укчы Федор карашындагы тәвәккәллек, карак бәндәләргә генә хас елгырлык исән.

– Безнең тарафка нинди җилләр китереп ташлады сине, сәфәрдәшем Федор? Син ничек мөселманнар арасына килеп чыгасы иттең әле болай?

Федор үзе дә гаҗәпләнүдән катып калган иде, ике кулы белән яңаклары буйлап аккан күз яшьләрен сөртә-сөртә, ниһаять, телгә килде.

– Теге чакта сиңа ярдәмгә килү – минем чират, дип шапырган идем дә, мәгәр бу юлы да, менә, синең капкыныңа мин килеп каптым, мине үлемнән йолып калу да янә синең карамакта. Ә сөйләсәң, озак, аһ, бик озактыр, морза. Кырым походыннан әйләнеп кайтканнан соң ниләр генә күрмәдем дә, нинди яман болганышларны кичеп чыкмадым мин! Барын-барын да түкми-чәчми сөйләп бирим дисәм, озын төн дә җитмәс.

– Ә минем ашыгасы җирем юк бит, балаларым да имчәк сорап, еламсырап ятмый. Вакыт – тик безнеке. Менә, ашарыңа гына китертәм дә, күңел бушатканчы сөйләшеп утырырбыз. Син Мәскәүнең үзендә гомер иткән кеше бит, ә мәркәздә бәян итәрдәй гыйбрәтле хәлләр күптер. Тез дә тез генә. Миндәй томанага Мәскәү хәлләрен якыннан белеп тору үтә фарыз бүген...

Асылда да, тамак ялгап алгач, мунча эченә бикләнеп, озак утырдылар. Федор үзе дә атна-айлар буе кеше күрми йөргәч, сөйләшүгә бик нык сусагандыр, катлап-катлап, кайта-кайта тезде.

– Мин Мәскәүдән түгел, ә үлемнән качып котылдым бит. Минем язмыш шундый хәерсездер. Ә Мәскәүдә хәлләр аңлатып та бетерә алмаслык яман. Анда ата – улны, ана – кызны белми. Федор патша үлеп киткән иде, тәмам мәхшәр купты. Бояр Милославский белән тирестән көрәк булган Нарышкиннар нәселе пычакка-пычак килеп, туктаусыз сугышалар.

Теләкәй кыяр-кыймас кына:

– Ничек тирестән көрәк була алган икән соң алар? – дип сүз кыстырып куярга мәҗбүр булды.

– Син аңлап та бетермәссең инде, Милославскийларның Мария атлы кызы – мәрхүм патша Алексей Михалычка беренче булып чыккан хатын. Ул үлеп киткәннән соң Алексей патшага икенче тапкыр өйләнергә туры килә, бу юлы аңа дворян Нарышкиннар үз кызлары Наталияны бирә. Алексей патша үзе үләр алдыннан тәхетне улы Федорга бирүне васыять итеп калдырган. Федор үзе исә чирләшкә бер йолкыш. Биш ел чамасы гына утырып тора алды да, аннан каюк.

– Һе, менә ничек ансат, – дип Теләкәй янә сүз кыстырып куйды.

Федор аңа игътибар да итми генә янә дәвам итте.

– Вәт менә шуннан соң Милославскийлар белән Нарышкиннар арасында сугыш башланды да инде. Алексей патшаның исән калган хатыны Наталия тәхеткә үз малаен, ун яше яңа гына тулган Петрны бердәнбер патша итеп утыртмакчы булган. Исәбе буенча, Петр бәләкәй чагында, ил белән шәхсән үзе идарә итәргә исәпләгән. Мәгәр Милославскийлар да бирешергә, майлы тагарактан читтә торып калырга һич тә теләми бит, шулар нахак юллар белән тәхеттәге Петр янәшәсенә мәрхүм Мария Ильиничнадан калган Иванны төртеп кертте. Анысына уналты яшь булса да, ул да Федор кебек үк чирләшкә һәм мокыт, үзенең мәнфәгате өчен сугыша да белми. Аның бәхетенә, патша Алексей Михалыч исән чакта дөнья куйган Мария Ильиничнаның беренче баласы Софья атлы ирдәүкә кызы да бар бит әле. Менә шул Софья дигән азгынны берәр боярга кияүгә дә бирә алмадылар. Ә егерме биш яшенә җиткән, өстәвенә үгез сыман ажгырып торган ялгыз хатын ни эшләсен, җан җиренә печән ашатып ята бирсенмени? Тоткан да, стрелецлар приказының башлыгы булып торган Васька Голицын белән өегә башлаган бу. Әнә шул Васька белән аның төнге сандугачына әверелгән Софья түнтәреш тә корып өлгергәннәр. Шулар котыртуына кушылып, без ахмаклар Кремльнең эченә бәреп кердек. Әллә ничә боярны сөңгеләр өстенә ыргыттык. Нарышкиннар нәселенең атаманы булган Артамон Матвеевның җанын шулай өздек...

– Әстәгыфирулла, йә Ходаем! – дип Теләкәй борын астыннан гына пышылдады.

– Менә шундый хәвефләрдән шөлләп, Нарышкиннар тәхеткә Иванны утыртып куярга да ризалашты. Хәзер тәхеттә, кеше көлдереп, борыннары юеш ике малай утыра, ә дилбегәнең асылы азгын Софья кулында. Без, бер күнегеп киткәч, фетнә давылын туктатмаган идек, Софья дворяннар гаскәре җыярга, дигән фәрман әзерләгән. Ул бит явыз, аның эче еланныкы төсле, кырыкмаса-кырык мәкер белән тулы. Дворяннар кузгалдымы, димәк, безгә каюк. Мин бит, сантый, Кремльгә иң беренче бәреп керүчеләр арасында булдым, Долгорукий дигән боярны да сөңгеләр өстенә үзем ташлаттырдым. Дворяннар белеп алса, иң беренче чиратта, мине дар агачына асып куячаклар, йә тегеләр шикелле үк, сөңге очына ташлап җанны кыячаклар. Менә шуңа чыгып шылдым да инде, Теләкәй морза. Тоташ гөнаһлы мин...

* * *

Укчы Федорның Теләкәйгә тезгән хикәяте хакыйкатьтән ерак түгел, ул айларда Мәскәү асылда да кан күленә кереп чумган иде.

Чирләшкә Федор Алексеевич аттан егылып имгәнүдән интегә-интегә вафат булып куйгач, патриарх Иоаким, тол патшабикә Наталия Кирилловнага ярарга тырышып, көнендә үк әле яңа гына ун яшен тутырган, колгадай яп-ябык Петр атлы малайны Кремль янәшәсендәге бер чиркәүдә яңа падишаһ дип игълан итәргә ашыкты.

(Ахыры киләсе санда)

Вахит ИМАМОВ

(Ахыры. Башы 41,42 нче саннарда).

Герой исеменнән мәхрүм калган 7 татар

Галләмов Әнвәр Галләм улы

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Әнвәр Биектау районының Таршна (Ташлы-?) авылында 1923 елда туган, 1942 елның февраленда Дөбьяз аша фронтка чакырылган. Аңа Сталинград, Үзәк, Брянск, 1 нче, 2 нче, 3 нче Белоруссия фронтларында сугышырга туры килгән. Өч тапкыр яраланган. Кызыл Байрак ордены һәм ике тапкыр «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Ул 48 нче армиянең 96 нчы укчылар дивизиясендәге 338 нче полкта медицина хезмәте буенча старшина була.

1944 елның 15 октябрендә Польша җирендәге Нарев елгасының уң як ярында сугыш барган чакта, ул яраланган 32 кызылармеецны аларның шәхси кораллары белән бергә яу кырыннан алып чыга. Яулар барышында мөмкинлек булган саен, кулына корал тотып, гитлерчыларның һөҗүмнәрен кире кагуда да катнаша.

1945 елның 26 февралендә Көнчыгыш Пруссиянең Загерн атлы авылы янында ул яу кырыннан авыр яраланган батальон командиры Гусевны алып чыга һәм медпунктка озата. Шул ук яуда тагын яралы 28 сугышчыны үлемнән коткара. 1945 елның 18 мартыннан 25 мартына кадәр Браунсберг шәһәре өчен яулардан 65 яралы сугышчыны алып чыга. 1945 елның 4-6 май көннәрендә Балтыйк буендагы Фриш-Нерунг борынында сугыш кырыннан 44 совет сугышчысын алып чыгып, аларны да, пулемет ротасы командиры капитан Сидоров белән үз ротасының командиры Чиковны да үлемнән коткара. 1945 елның 13 маенда аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр, ләкин югарыдагылар фәрманы аны икенче мәртәбә Кызыл Байрак орденына лаек дип таба.



Галиуллин Идият Сибгатулла улы


НАГРАДНОЙ ЛИСТ



Ул 1923 елда Казанда туган, 1943 елның 9 июнендә Дзержинск комиссариаты аша яуга озатылган. 1 нче Украина фронты составында сугыша, яралана, Кызыл Йолдыз орденына лаек була. 372 нче үзйөрешле артиллерия полкында механик-йөртүче булып хезмәт итә, өлкән сержант.

1945 елның 16 нчы һәм 23 нче апрель арасында Идият экипажы 2 «Тигр» танкын, 4 үзйөрешле «Пантера»ны, 2 бронетранспортерны яндырып юк итә, 2 артиллерия батареясын һәм 30 пулемет ноктасын, 50 автомашинадан торган дошман колоннасын, 260 ка якын гитлерчыны сафтан чыгара. Яулар барышында авыр яраланса да, Идият үз постын ташлап китми. 1945 елның 28 апрелендә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителәм, ләкин татарларның каһарманлыгы очсызланган вакыт, аны Кызыл Байрак ордены белән генә бүләклиләр.

Галәүтдинов Мәгъсум Галәүтдин улы

Татарстандагы Биектау районының Татар Айшәсе авылында 1926 елда туган, шул ук район хәрби комиссариаты аша 1943 елның 11 ноябрендә сугышка озатылган. 1944 елның 8 июненнән 1 нче Белоруссия фронтында яу йөри, 3 нче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. 47 нче армиядәге 143 нче дивизиясенең 487 полкында 76 миллиметрлы орудиенең төзәп атучысы булып хезмәт итә.

1945 елның март аенда Мәгъсум Германиянең Дойч Кроне шәһәре өчен сугыш барышында туры наводка белән атып, дошманның бер ДОТын һәм 2 пулеметын сафтан чыгара. 1945 елның 30 апрелендә аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. Ул Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

Ул ясаган күп детальле, бай эчтәлекле, бер күрүдә истә кала торган үзенчәлектәге картиналар белән танышуга ук күңелдә шатлык хисләре туа. Рәссамның исеме дә гарәпчәдән «шатлык, куаныч» дип тәрҗемә ителә. Ул, чын талант иясе буларак, тыйнак шәхес. Шуңадыр, аның әсәрләренә карагач та, «Тирән елга тын ага» мәкале искә төшә. Бу рәссам беркайчан да үзе хакында сөйләми, ул бар хис-тойгыларын, тормыш фәлсәфәсен берсеннән-берсе матур әсәрләрендә чагылдыра.

ТИРӘН ЕЛГА

Яр Чаллы каласында яшәп иҗат итүче, ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы Тәслия Мәҗитова 1957 елның 21 июлендә Мөслим районының Сөякәй авылында туган. «Безнең авылыбыз тарихы 1795 елдан бирле мәгълүм. Ул борынгы чыганакларда да искә алынган. Биредә мәчет, мәктәп, су тегермәне булган. Инкыйлабтан соң манарасы киселеп, бинасы башта – мәктәп, аннары клуб итеп үзгәртелгән мәчетебез бар иде, тик аның язмышы аянычлы тәмамланды...» – дип искә алды ул әңгәмә башында ук. Ә аннары туза барган элеккеге мәчет бинасын инде яндырып, көл иткәннәр икән... Шушы борынгы мәчет тарихын ул кечкенәдән бирле күңел түрендә саклый. Әлеге бинада урнашкан мәктәптә башлангыч белем алгач, Тәслия Әмирхан кызы укуын Әмәкәй авылындагы сигезьеллык мәктәптә дәвам иткән, аннары инде – Күбәк авылында... Ә ул авыл Сөякәйдән ун чакрымнан артык ераклыкта урнашкан. Урта мәктәпне тәмамларга кирәк бит, кар-буранмы, җил-яңгырмы, ун чакрым юл һәр көн җәяү үтелгән, белем хакына барысына да түзелгән... Тырышлык, сабырлык сыйфатлары да, белемгә көчле омтылыш та шушы еллардан ук килә. Юкса, гаилә куаныч-мәшәкатьләре дә өстәлгән чорда, нәкъ 40 яше тулгач, ул Яр Чаллы дәүләт педагогика институтына укырга керер идеме икән?..

Ниһаять, әлеге хатирәләрен барлап, авылдашларының, газиз әтисенең мәчет тарихы хакында әрнеп сөйләгәннәрен дә оныта алмыйча, ул шул мәчет сурәтен киндергә ясарга булган. «Һәм мин аны бер утыруда, 2-3 сәгать эчендә ясап та бетердем, – диде рәссам ханым. – Моңа кечкенәдән бирле әткәй-әнкәй тәрбиясеннән сеңгән Аллаһы Тәгаләбезгә ышану, иман көчем дә булышлык иткәндер. Мин мәчетнең яндырылган мәлен сурәтләдем. Шушы «Мәчетебез язмышы» картинамны Түбән Каманың Ә.Фәтхетдинов музеенда ачылган күргәзмәмдә күрүчеләр дә истә калдырды, югыйсә, ул күргәзмәгә нинди генә хезмәтләрем эленмәгән иде, ә кызым Ләйсән исә аны гомумән дә тетрәндергеч сурәт дип атады.

Җаным-тәнем белән авылга бәреккән мин. Аның бар җисем-ядкяре, табигате, иген кырлары, болыннары, өч инеше һәрвакыт күз алдымда тора. Туган ягымны сагынсам, аны киндерләрдә тасвирларга тотынам...

Картиналары Россиядәге бик күп шәхси тупланмаларда, Чистай мөхтәсибәтендә, Алабуга, Чирмешән районнарында, Түбән Кама, Әлмәт, Мөслимнең туган як музейларында, Чаллы картина галереясында саклanучы иҗатчының һөнәри юлы Лениногорск педагогика училищесының сынлы сәнгать-графика бүлеген тәмамлагач башланган. Ул әлеге училищены 1979 елда рәсем сәнгате, сызым укытучысы белгечлеге буенча тәмамлаган һәм Әмәкәй мәктәбендә балалар укыта башлаган. «Берьюлы өч сыйныфны укыту бик җиңел булмады, 22 кечкенә бала күзләремә генә карап тора, тәҗрибәм юк, әмма шулай да бер ел буе укыттым, ата-аналар җыелышларын да уздырдым, караңгы чырай күрсәтүче булмаса да, түздем. Укыту процессы минем өчен түгелдер кебек тоелды. Күрше авылда балалар бакчасы ачылгач, шунда күчтем, соңрак янә Октябрь сигезьеллык мәктәбендә белем бирергә туры килде. Һәм 1984 елда Яр Чаллы каласына килдем. Миңа нибары 26 яшь, әле гаилә дә кормаган чагым, «КамАЗ»ның Автомобильләр җыю заводына рәссам-бизәүче булып урнаштым. Эшемне бик ошатып башкардым. Аннары инде гаилә корып, ирем Гамил белән Альберт улыбызны, Ләйсән кызыбызны үстердек. Бүген улыбыз – төзүче, кызыбыз – рәссам-проектлаучы. Кызым төсләр гармониясен яхшы белә, ул да кул эшләнмәләре остасы, сәйлән белән картиналар чигә.

Миннән еш кына: «Сез картиналарыгызны ничә яшьтә яза башладыгыз?» – дип сорыйлар. Мин: «40 яшемдә», – дигәч, бик гаҗәпләнәләр. Сез дә гаҗәпләнерсез», – диде рәссам ханым. Һич юк, бер дә гаҗәпләнмим. Аның иҗатындагы натюрмортлар, пейзажлар, сюжетлы композицияләр, портретлар – барысы да сокландыргыч матур! Алардан үз милләтенә, татар мәдәниятенә, гамәли сәнгатенә булган мәхәббәт бөркелеп тора, аларга һәркем мөкиббән китәрлек. Шуңа күрә Тәслия Әмирхан кызына башка сорау бирәм:

– Сезнең хиссиятле, экспрессив иҗатыгыз реалистик сынлы сәнгать мәктәбе кануннарына нигезләнсә дә, импрессионизм юнәлешендә булса да, техник башкарылышы буенча барыбер үтә гаҗәпләндерә. Сез иң беренче җитди картиналарыгызны да нәкъ шушы ысулны кулланып яздыгызмы?

– Миңа 40 яшь чакта, бер дус ханым: «Әйдә, Чаллы педагогика институтына укырга керәбез», – дип тәкъдим итте. Тәвәккәлләдек. Аның белән институтның сынлы сәнгать-графика факультетында читтән торып укый башладык. Ә ул курска, ни хикмәт, ярты төркем – яшьләр, ярты төркем олырак яшьтәге студентлар җыйналды. Уку чорыбыз бик күңелле үтте. Эшләремдә күбесенчә ел фасылларын тасвирладым. «Рабига күле» дип аталган 2002 елгы диплом эшем дә Болгар табигатенә багышланды. Аны язу өчен язын ук иремне, улымны иярттеп, шул якларга барып кайттым.

Мин әүвәл пейзажлар иҗат иттем, аннары гына натюрморт жанрына күчтем. Бу техниканы мин бер сүз белән болай дип аңлатам: кулым шундый. Мондый ясау рәвеше, әйтерсең лә, үзеннән-үзе барлыкка килде. Җаным шулай итеп ясарга теләде димме инде...

Әнием Әсхия дә, әтием Әмирхан да гомер буе колхоз эшендә булды. Әтием тракторчы иде, басудан кайтып кермәде. Табигатьне яратуым – әтиемнән килә, ахрысы. Кайчак: «Агроном булсам, басуларда гына йөрер идем!» – дип тә уйлап куям хәтта. Чөнки әткәй хезмәте кергән, ул сөргән киң кырларга, зәп-зәңгәр күккә, җылы җилләргә, офыкка кадәр сузылган алтын башаклы басуларга карап, барысына соклану – балачактан бирле. Мин табигатьне яратам, һәммә чәчәкләрне, әмма алар арасыннан бигрәк тә ромашкаларны үз итәм. Мин бар Җиһанны яратам! Мин кешеләрне дә бик яратам һәм шул ук вакытта кешеләргә ачу да саклый белмим. Дөньяны шулай, бары куанып кабул итүем барлык хезмәтләремдә дә ачык чагыла.

Әнием рәсем ясавымны бик теләде! Рәсемнәремне ошаткандыр инде. Институтта укыганда бит өй эше итеп бирелгән төрле этюдларны да күп ясарга кирәк иде, тышта кар яуса да, әнием миңа: «Бар, рәсем ясап кайт инде», – дия торган иде. Менә шулай итеп, белемнәремне тагын да ныгыта башлагач та, 40 яшемдә кулыма янә кылкаләмнәр алып, каршыма чиста киндер, майлы буяулар куеп, илһамланып картиналар яза башладым. Беренче шәхси күргәзмәмне 48 яшемдә 2005 елда Чаллы картина галереясында ачтым.

– Сезнең шушындый, дулкынлы энергия тибрәлеп торгандай итеп язылучы әсәрләрегез нинди атмосферада туа?

– Алар тулы тынлыкта языла. Бу вакытта миңа бернинди көйләр дә комачау итәргә тиеш түгел. Арка ягыннан карап торучы да булмаска тиеш. Мин бар күңелемне биреп, 3 сәгать язам. Аннан да артык вакыт ясап утыра алмыйм. Язганда башым уйлар белән тулы була, кулларым ясап тора... Картина язганда, энергия күп түгелә. Бу хакта бар рәссамнар да искәртәдер. Әйе, әсәрләремдә этнографиягә басым ясыйм, халык гореф-гадәтләрен тасвирларга тырышам. Картиналарым күп. Аларның берникадәре күмәк пленэрларда да ясала. Мәсәлән, быел без Мөслимдә Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивале кысаларында оештырылган этнопленэр үткәрдек, анда илебезнең илле ике рәссамы җыелды, чара көннәрендә ясалган кырыкка якын эшебезне мөслимлеләргә бүләк итеп калдырдык, халык белән теләп аралаштык. Гомумән, җиде дистәгә якын үз картинамны төрле оешмаларга, мәдәният йортла-

ТЫН АГА

рына бүләк итүче рәссам дә мин.

– Тәслия ханым, сез үз иҗатыгызда натюрмортлар ясауга өстенлек бирәсез...

– Әйе. Әмма вакыт-вакыт сюжетлы композицияләр дә ясыйсы, кеше сурәтләренә дә алынасы килә. Күңел халәте үзгәреп тора. Бу һәр рәссамга хас... Мин чыннан да тирә-юнь мохиттагы предметларга, савыт-сабага игътибарлы. Кечкенә чакта ук әниемнең кул эшләнмәләрен күреп үстем. Мин генә түгел, өч бертуган энем дә аларга сокланып туймады. Без шул ямьле чигешләрне күреп, ясарга өйрәндек дә инде. Сәләт булгач, энеләрем дә мәктәп стена газеталары рәссамнары булып танылды, алар хәзер дә йә шигырь яза, йә рәсемнәр сызгалыйлар әле.

Өебездә әнкәйнең чигүле мендәр тышлары, тәрәзә пәрдәләре, кульяулыклары, ыргак белән бәйләнгән тастымал башлары, башка челтәрле әйберләр күп иде. Хәзер аларны үземдә кадерләп саклыйм. Шуларны һәм авылда кирәк булган көнкүреш әйберләрен кулланып, натюрмортлар язам. Алар берничә дистә инде... Әйтик, әнием кул эшләнмәләрен тезеп, янәшәгә талбишек тә куеп, «Бишек җыры» дигән әсәремне дә яздым, «Чулпы чыңы. Әнкәйгә истәлек» картинам да нәкъ шулай иҗат ителде.

Натюрмортларымны ошаталар, юбилеем уңаеннан ачкан шәхси күргәзмәмә килгән Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев та үз чыгышында: «Бу күргәзмәне күрер өчен махсус килдем, ерак юллар үтеп, бирегә кадәр килүемә бер дә үкенмим, күңелем матурлык белән тулды!» – диде. Мондый җылы бәяләмәләр һәр рәссам өчен дә көтеп алынган шатлык. Без бит картиналарыбызны халык өчен язабыз. Узган ел, 65 яшьлек юбилеем уңаеннан, «Туган як җылысы» күргәзмәмне Яр Чаллы, Түбән Кама, Мөслим тамашачыларына күрсәттем. Шәхси күргәзмәне, кайчан да булса, башкалабыз Казанда да ачарга хыялланам.

– Сез, белгәнемчә, әле дә эшлисез?

– Әйе, Чаллының 52 нче татар урта мәктәбендә рәсем дәресләрен алып барам. Укучыларымны натюрмортлар, милли тематикадагы рәсемнәр ясарга өйрәтәм, мин аларны катгыйлык чигендә тотып укытмыйм, иркенлек бирәм, теләгәннәре класс буйлап йөреп, башка иптәшләренең рәсемнәренә дә күз төшереп килә ала. Укучыларымның берничәсе шушы һөнәрне сайлап, Казан, Мәскәү югары уку йортларында да укый. Укыту тәҗрибәм бар, моңа кадәр дә калабызның 2 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укытучы булып эшләгән идем. Хәзер рәсем укытучылары өчен Россия күләмендә төрле бәйгеләр дә оештырыла башлады. Быел мин дә Мәскәүдә узган шундый бәйгедә «Сынлы сәнгать» номинациясендә җиңеп, I урынга лаек булдым.

Өч оныгыбызның берсе – II сыйныфны тәмамлаган Энҗебез рәсем ясауга бик һәвәс. Ясый башласам, шул минутта ук янәшәмә килеп баса, аңа рәсем ясауда бары да кызык, үскәч, әгәр дә шушы һөнәрне сайласа, шат булыр идем, тик ата-анасы гына моның белән килешмәскә мөмкин. Ни дисәң дә, һәрбер рәссамга да уңыш юлдаш булмый.

– Алдагы көннәр белән бәйле тагын нинди максат-планнарыгыз бар?

– Мин – ТР «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасының Яр Чаллы бүлегендә. Быел апрельдә Бөтендөнья татар конгрессы белән «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы оештырган

III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съездында да катнашырга насыйп булды, анда ачылган күмәк күргәзмәгә дә үз өлешемне керттем. Хәзер рәссам Рауза Иванова-Латыйпова белән бергәләп, «Ак калфак»ның Чаллы бүлеге әгъзаларын да туплап, республика яисә халыкара күләмдәге «Ак калфаклы рәссамнар» оешмасын төзергә ниятлибез. Татарстанда, Россиядә гомер итүче хатын-кыз рәссамнарның, декоратив-гамәли сәнгать осталарының иҗат эшләрен туплап, күп кенә күчмә күргәзмәләр ачарга хыяланабыз. Безне Уфага, Австралиягә, Кытайга да чакырдылар инде, чөнки сынлы сәнгать әсәрләре бүгенге көндә аеруча популяр. Картиналарның миллилек ягы буенча аерылып торуларын телибез, безгә гомуми глобальләштерү кирәкми. Менә сез дә бит иҗатымны нәкъ менә милли төсмерләрдә булганы өчен искәрттегез.

– Шулай. Зур шәхси күргәзмәгезне Казан сәнгать сөючеләренә, сәнгать белгечләренә дә тәкъдим итәргә насыйп булсын!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

«ЕЛЬЦИН ТҮБӘТӘЕ»

90 еллардагы милли хәрәкәт белән таныш кешеләр «Ельцин түбәтәе» дигән гыйбарәне яхшы беләдер. 1990 елда «Йота алган кадәр суверенитет алыгыз» турындагы чыгышыннан соң, Ельцинга бер агай – Аксубайдан Зөфәр Салиев түбәтәй кидерә. Аннары… шул түбәтәен кире сорап хат яза. Зөфәр Салиевның улы белән очрашып, бу вакыйгаларның нечкәлекләрен ачыкладык.

«Суверенитетны үзегез йота алган кадәр алыгыз» (Берите суверенитета столько, сколько вы его сможете проглотить) – РСФСРның Югары Советы рәисе, соңрак – Россиянең беренче президенты Борис Ельцинның 1990 елның 8 августында Казан университетында җәмәгатьчелек белән очрашу вакытында әйткән сүзләре. Ул бу чыгышын: «Мин һәр республиканың милли үзаңы үсешендә тоткарлык буласым килми», – дип дәвам итә. Шушы чыгышыннан соң, милли хәрәкәт активисты Зөфәр Салиев аңа түбәтәй кидерә.

● Зөфәр Салиев.



● Зөфәр Салиевның улы Равил.

Соңрак Борис Ельцин бу сүзләрен башка кабатламый. Россия һәм Татарстан арасында вәкаләтләрне бүлешү турындагы сөйләшүләр башлана. «Коммерсантъ» язуынча, 1992 елның 12 апрелендә Казанда узган митингта Ельцинның түбәтәйне кире кайтаруны таләп итәләр. Соңрак, өметләре акланмаганны аңлаган Зөфәр Салиевның түбәтәйне кире таләп иткән, «Түбәтәйне кайтарыгыз!» дигән мәкаләсе дә чыга.

«Азатлыкка күтәрелгән татар халкы сезне зур хөрмәт белән, демократ буларак каршы алды, сездә үзен яклаучы, кимсетелгән халыкларны яклаучы сәясәтчене күрде… Сез Казанда үзегезне нәкъ шулай күрсәттегез… Әмма сез мине һәм минем кебек миллионнарны алдадыгыз. Президент булгач, сезнең битлек астындагы президент иканлеге, икейөзле булуыгыз аңлашылды… Бездә бирелгәнне кире сорау гадәте юк. Әмма, кызганычка, мин моны эшләргә мәҗбүр. Бездә изге милли баш киеме булган түбәтәйне кире кайтарыгыз. Сез аңа лаек түгел!» – дип яза Зөфәр Кәшәфетдин улы «Молодежь Татарстана» газетасында 1996 елның гыйнварында чыккан мәкаләсендә.

Зөфәр Салиев истәлекләреннән: «Срочно түбәтәйне җибәр!»

Зөфәр Салиев 2020 елның сентябрендә вафат булды. Аңа ул чакта 96 яшь иде. Ул – Бөек Ватан сугышы ветераны, Иске Кармәт авылыннан. Нәбирә Гыйматдинова «Ватаным Татарстан» газетасына аның яшь чагында Донбасс шахталарында эшләвен яза. Мурманскида «Морской охотник» дип аталган хәрби корабларны эзәрлекләү частенда хезмәт итә. Аннары ул Иске Кармәттә, аннары Ульян өлкәсендә, соңрак Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылында укыта. 1969 елда Чирмешән районы Иске Кармәт авылына директор итеп җибәрәләр. Анда ул 13 ел эшли, үзе – география, хатыны Оркыя ханым тарих укыта. Агач мәктәп урынына таш мәктәп салдыра, ул мәктәптә әле дә укыйлар. Нәбирә Гыйматдинова язуынча, ул Хәсән Туфанны аклар өчен дә суд юлларын да таптаган. Зөфәр Салиев үзе тарих белән кызыксыну сәбәпле, милли хәрәкәткә килүен, 1989 елдан Казанда яши башлавын искә ала. Ул Муса Җәлил һәйкәле янындагы митингта Татарстанның союздаш республика булырга хокукы турында чыгыш ясый, халык моны бик ошата, аны хуплый. Моннан дәртләнеп киткән Зөфәр Салиев милли хәрәкәткә башы-аягы белән чума. Митингларда даими катнаша, чыгышлар ясый, Ирек мәйданында ачлык игълан итүчеләр төркеменә кушыла.

Ельцинга түбәтәй кидерү турында ул болай искә ала: «Россия Президенты Ельцинның Казанга килүе үзе бер тамаша булды. Президентны күрәсе килә. Рәхмәт, Казан дәүләт университеты парторгы чакыру кәгазе бирде. Халык шыгрым. Алда ике якка да микрофон куйганнар. Безнең мөстәкыйльлеккә кизәнгән рус демократлары чәчрәп чыга да Ельцинга сораулар яудыра. Менә зур кунак сөйләргә керешә. Кызым Роза миңа кыйммәтле түбәтәй бүләк иткән иде, сәхнәгә менеп кигездем дә куйдым шуны Ельцинның башына! «Хөрмәтле Борис Николаевич, әгәр син безнең мөстәкыйльлекне якласаң, сине пәйгамбәр урынына күрер идем», – дидем. Ул аркамнан какты, һәм без куллар кысыштык та, мин аска төштем. Ельцин: «Берите суверенитета столько, сколько хотите», – диде, «күпме йотасыз» дигән сүз әйтмәде кебек. Мәскәү мөстәкыйльлеккә бәйләнә башлагач, мин ике көн саен «Правда», «Известия» газеталарына һәм шәхсән Ельцинга: «Срочно түбәтәйне җибәр, син аңа лаек түгел», – дип телеграммалар суктым...»

Туксанынчы елларда Зөфәр Салиев гел түбәтәйдән. Ул ачлык мәйданында да була, ул чорда аның хакында еш язалар. Нәбирә Гыйматдинова аны «милли хәрәкәт үзәгендә кайнаган, пенсия акчасына татар китаплары, Коръән тәфсирләре сатып алып тараткан» шәхес буларак, бик югары бәяли.

Зәки Зәйнуллинның «Ачлык мәйданы» китабында да аның хакта сөйләнелә. Анда Зөфәр Салиевның түбәтәен ишегалдында домино уйнап утырган кешеләр салдырып алуы турында сүз бара. Зәки Зәйнуллин 3 егет белән ишегалдына кереп, теге кешене бугазлап, түбәтәйне кире кайтаруын яза. Дөрес, соңрак чыккан «Кеме генә юк татарның?» китабында Зәки Зәйнуллин шушы ук эпизодны бераз башкачарак сурәтли, Зөфәр Салиевка гаеп тә ташлый, «махсус хезмәтләр агенты» дип гаепли. Нәбирә Гыйматдинова, Зәки Зәйнуллинның үз сүзләренә таянып, бу гаепләүләрне кире какты.



● Ельцинга беренче кидерелгән түбәтәй шушы булып чыкты. Д.Бунтуков фотосы.

Зөфәр Салиевның улы Равил дә этисе кебек үк педагог. Биектау районы Пермяки авылында 27 ел буе мәктәп директоры булып эшләгән. Хәзер – һәвәскәр тарихчы, төбәкне өйрәнеп, китаплар яза. Ул этисе белән булган шушы вакыйгаларны искә алды. «Рус авылында эшләдем», – дип, ул башлыча русча сөйләде.

– Әтием Зөфәр Салиев – тумышы белән Аксубай районы Иске Кармәт авылыннан. Бу – Хәсән Туфанның туган авылы, алар безнең белән күршеләр булган. Мәгълүм ки, Хәсән 14 яшендә, бәхет эзләп, Уралга китеп барган, шахталарда эшләгән. Ул бер чыгып киткәннән соң, 54 ел буена туган авылына бер тапкыр да кайтмый.

1971 елда әти аны беренче тапкыр Иске Кармәткә кайтырга күндерә. Бу бөтен җирдә дә документаль рәвештә кереп калган. Хәсән Туфанның бөтен биографиясе, арттырып әйтү түгел – барысы да минем әтинең сүзләреннән алып язылган. Язучы Н.Гыйматдинова да «Дәрвиш хатирәләре» әсәрендә әтинең Х.Туфанны ничек туган якларына алып кайтуы, ни өчен аның монда кайтмаска тырышуын язды.

Ни өчен шулай булуы хакында фаразлар күп. Әтинең сүзләренә караганда, Хәсән Туфанны кулга алгач, органнар Иске Кармәт авылыннан характеристика сорап алган. 3 кеше кул куйган характеристика килә: парторг, авыл советы рәисе һәм колхоз рәисе. Аны мулла нәселеннән, «халык дошманы» дип язалар. Бәлки, шуңа күрә күңеленнән рәнҗеп калгандыр. Туфан моннан соң әле тагын 2 тапкыр Иске Кармәткә кайта. Әтием Хәсән Туфан белән бик дус иде. Хәтта минем апам һәм абыемның Туфаннарда кунганы да бар, ялгышмасам, Маяковский урамында иде фатиры. Мин үзем анда бер тапкыр да булмадым.

Хәсән Туфан белән үзем дә бик күрешергә теләгән идем, ул безнең күрше бит инде. Ләкин берничек тә очраша алмадым. Бер генә тапкыр күрергә язды. 1975 елда Казан педагогия институты дипломын алгач, тимер юл вокзалына – авылга билет алырга киттем. Без ул вакытта Иске Кармәттә түгел, Чирмешән районында яши идек, эти мәктәп директоры булып эшли. Поездга кадәр вакыт уздыру өчен, Колхоз базарына кереп, күчтәнәчләр алдым. Шунда Хәсән Туфанга охшаган ак башлы кеше күрдем. Портреты буенча таныдым – ул мин яшәгән тулай торактагы бүлмәдә эленеп тора иде. Мин аның белән бик горурланып яшәдем. Уку елы тәмамлануга, югалмасын өчен, ул портретны төреп алып кайтып китә идем. Базарда Хәсән Туфан бер хатыннан өрек алып тора. Хатын-кызлар үзара сөйләшә, «бу – шагыйрь Туфан бит» диешәләр. Берәү килде дә: «Хәсән ага, тизрәк кыймылда, ашыгабыз», – диде. Мин, бәлки, борылып алганмындыр, шул арада Туфан юкка да чыкты. Ябык түбәле базардан чыктым – Туфан Бауман урамына, Нәшрият йортына таба барып ята. Мин артыннан киттем, ләкин

● Язучылар берлегендә Ельцин белән очрашу. Владимир Зотов фотосы.

● Яңа мәктәп янында коллектив белән күмәк фото. Фото: © nashcheremshan.ru

ТАРИХЫ

ВЕРНИТЕ ТЮБЕТЕЙКУ!

ПИСЬМО В НОМЕР

Президенту Российской Федерации
Борису ЕЛЬЦИНУ

Господин Президент!

Зуфар Кашафутдинович САЛЕЕВ,

РАЗБОРКИ НЕДЕЛИ

...морощенный спрут?

● «Молодежь Татарстана», 1996 елның гыйнвары.

артыннан килеп, эндәшергә, «Хәсән ага, мин сезнең туган авылыгыздан», – дип әйтергә кыймадым.

Әти белән аларның яшь аермасы бик зур иде. Ләкин әти аралашучан кеше иде, алар дуслаша алганнар. Әтием Хәсән Туфанга мамык мендәр бүләк иткән. Бу хакта Рәшит Әхмәтҗановның шигыре дә бар.

– Ельцинга түбәтәй бүләк итү ничек булды?

– Минем әти – Ельцинга түбәтәй бүләк итүе белән дә бөтен республикага танылган кеше. Бу хәл Казан университетында очрашуда була. Бу түбәтәй турында ялкау язучы гына язмагандыр. Ялгышмасам, беренче булып Венера Якупова язды. Ул болай дипраслый: әтием түбәтәйне Ельцинның күңелен йомшарту, ул Татарстан республикасына суверенитетны күбрәк бирсен өчен, дип бүләк иткән. Ләкин бәйсезлекне алай күп бирмәвен аңлагач, түбәтәйне кире кайтарсын, дигән таләп белән, әтиемне мәкалә язарга күндерәләр. Әтием: «Ельцин, син бәйсезлекне без сораган кадәр бирмәдең, шуңа күрә син татар түбәтәе кебек затлы бүләк кияргә хакың юк», – дип язган. Апам сүзләренә караганда, әти бу түбәтәйне Үзбәкстаннан алып кайткан. Ул – затлы түбәтәй, кыйбатка сатып алган булган икән.

– Кайтардылармы?

– Юк инде. Казан ханнарының таҗы да Мәскәүдә саклана – аны да кайтармадылар бит, түбәтәйне инде бигрәк тә. Әмма ул түбәтәй турында әллә нинди мәзәкләр сөйләп йөрделәр. Имеш, Казаннан Мәскәүгә очып киткәндә, Ельцин бу түбәтәйне очкыч тәрәзәсен ачып җиргә ташлаган икән, ди.

– Сез – Ельцинга түбәтәй бүләк иткән мәшһүр кешенең улы, түбәтәй хәзер кызганыч түгелме соң?

– Кызганыч дип әйтә алмыйм. Кирәккәндер инде әтигә бүләк итәргә ул чагында. Әти өметләнгәндер, халыкта бит «ирек алабыз» дигән өмет бар иде бит, ләкин ул ирекне без алып бетерә алмадык. Үзегез беләсез, Шахрай килгән иде, Емельян Пугачевның читлеген кулына тотып, безнең президентыбыз Шәймиевне шул читлеккә утыртып, Казаннан Мәскәүгә алып китеп хөкем итәргә теләгән иде, халык президентыбызны ул вакытта яклап калды, бирмәде. Ә Сергей Шахрай ул читлекне буш килеш үз урынына кайтарып куйды. Минемчә, түбәтәй Мәскәүнең дәүләт тарих музеендадыр.

– Түбәтәйне табып, кайтарасы килмиме?

– Аны табып була микән инде хәзер? «Ельцин ташлаган» дигән сүз мәзәкләр, мин аңа ышанмыйм. Свердловскида Ельцин үзегендә булдым. Карап йөрдем, әтинең түбәтәе бу үзәктә куелмаган микән, дип. Кызганычка, озак йөри алмадым, күрмәдем.

Ркаил Зәйдулла бу вакыйгалар турында 1999 елда чыккан китабында болай телгә ала (мәкалә 1991 елның ноябрендә язылган):

«Ә түбәтәй кайда ята икән соң? Югалмаган микән? Киләчәктә урыслар аны, Казан бүреген саклаган кебек, затлы музейларына куярлармы?

Кешеләр төрлечә уйлый. Казан бүреген кире бирмәделәр, хет бу түбәтәйне кире кайтарырга иде, ялгыш кидергәнбез аны Ельцинга, диючеләр дә бар. Хәтта Салеев фамилияле бер карт Мәскәүгә телеграмма да суккан икән: «Ельцин, түбәтәйне кире җибәр, син аңа лаек түгел!»

Менә юләр димә инде син аны! Мәскәүгә җибәрелгән әйбернең кире Казанга әйләнеп кайтканын кемнең кайчан күргәне бар әле?!»

Түбәтәй кайда?

Зөфәр әфәнденең улы Равил әйтүенчә, бу түбәтәй фотосы беркайда да юк. Интернетта Дмитрий Бунтуков төшергән түбәтәйле фото бар. Шуны башта Зөфәр абыйныкы дип уйлаган идем. Әмма Ельцин артындагы Тукай сурәтен шәйләп, хезмәттәшем Рузилә Мөхәммәтова моның Казан университеты булуына шик белдерде. Казан университетында Тукай фотосы була алмый бит инде 90 нчы елда! Әле хәзер дә аның булуы шикле. Чыннан да, тикшеренә башлагач ачыкланды – 8 август көнне Ельцинга 2 түбәтәй кидергәннәр икән! Берсен – Тукай клубында, икенчесен – университетта. Ул ике урында халык белән очрашкан.

«Ельцинга беренче түбәтәйне мин кидердем, – ди язучы Ринат Мөхәммәдиев. – Мин аңа: «Бу татар түбәтәе башыгызны сакласын!» – дип әйтеп кидердем. Ринат Мөхәммәдиев, билгеле, түбәтәйне кире сорау турындагы вакыйга турында хәбәрдар. Әмма ул үзенең түбәтәен кире сорамавын әйтте. «Биргән бүләкне кире сорауны дөрес дип санамыйм», – диде ул.

Журналист Любовь Агеева язуынча, Борис Ельцин ТАССРда 6 сыннан 9 ына кадәр була, Әлмәт, Чаллы, Алабугада да була. Нәкъ менә язучылар белән очрашканнан соң ул трамвайга утырып китә дә инде. Язучылар йортыннан чыккач, аны транспарантлар тоткан кешеләр каршы ала. Каршына күп кешеләр килүен күргәч, ул хөкүмәт автомобильләре торган якка түгел, ялгыш башка якка китә. Министрлар Кабинеты хезмәткәре Рөстәм Мәндиев, трамвайның светофорга туктаганын күрә. Йөртүче ханым, Ельцинны күргәч, ишекне ача. Ул трамвайга утырып китеп тә бара. Трамвайны туктатып, машинага күчереп утырталар.

Ельцин «Архиерейская дача»да яши. Моторлар төзү идарәсендә аны Татар иҗтимагый үзәге активистлары урамда көтеп тора. Ул урамга чыгып, шул плакатларны укый. Рәүф Ибраһимов: «Без Россиягә кермәдек» дигән плакат тотып торган була. Ул шуны укыгач, дәшми тора һәм китеп бара.

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.

Рәшит Әхмәтҗановның Зөфәр Салиевка багышлап язган шигыре:

«Мамык мендәр»

Туфан туган авылдан ул.
Һәм бераз охшый Туфанга.
Охшагандыр – бу дөньяны
Күз яше белән юганга.
Һәр әйткәне шигырь аның,
Нигә соң ул үзе язмый?
Менә тагын яңа шигырь
Сөйли миңа Зөфәр абзый:
«Исләремдә исән тора
Туфан илгә кайткан көннәр.
И-и-и, ул көннәр...
Мин шагыйрьгә
Бүләк иттем мамык мендәр.
Кайткан көннүк йолдызларга,
Ай-Кояшка ник мендәргә? –
Йокласын дим, ял итсен бер
Башын салып шул мендәргә.
Уйлагандыр: «Халкым һаман
Кемнәргәдер билен бөгә.
Татарларым кол булганда –
Бу азатлык миңа нигә?!»
Кабат ташка әйләнгәндер
Шул чагында мамык мендәр.
И-и-и, шагыйрьнең бар гомере –
Айлы төннәр, кара көннәр…»
Сөйли шулай Зөфәр абзый.
Ул – Туфанның авылдашы.
Күз алдымда... мамык мендәр
Һәм... күгәргән зиндан ташы!

Якутиядәге Милли китапханәдә Татар әдәбияты һәм мәдәнияте үзәге ачылды

Татарстан Милли китапханәсе хезмәттәшлек турында килешү кысаларында Саха Милли китапханәсенә Татарстанның мәдәни һәм тел мирасын популярлаштыру һәм саклау өчен 700 китап бүләк итте. Бөтендөнья татар конгрессы Якутиянең Татар әдәбияты үзәгенә шулай ук китаплар тапшырды.

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте үзәгендә Татарстан тарихына, аның символларына, күпмилләтле мәдәниятенә һәм халык традицияләренә багышланган китаплар тәкъдим ителде. Күргәзмәдә балалар әдәбияты да куелган иде, ул Балалар уку үзәгенә тапшырылачак.

«Татар әдәбияты һәм мәдәнияте үзәген ачу идеясе тугандаш халыкларыбызны якынайтудан гыйбарәт. Шулай ук үзәк яшь буынга патриотик тәрбия бирүгә ярдәм итәчәк, бу балалар, бездән ерак, башка милли республикалардагы яшьтәшләре белән дус яшәргә мөмкин булуын аңласын өчен

эшләнә. Очрашуга килгән һәм китапханәдә даими эшли торган күргәзмәне оештырырга ярдәм иткән барлык кешеләргә рәхмәт белдерәсем килә», – диде «Туган як» Татар мәдәни үзәге рәисе Игорь Хәлилов.

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте үзәге Татарстан Милли китапханәсе, Саха Республикасы Мәдәният һәм рухи үсеш министрлыгы (Якутия), Саха Тышкы элемтәләр һәм халыкларның эшләр министрлыгы ярдәмендә «Татарстан Республикасында якутлар милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы инициативасы белән ачылды.

Бөтендөнья татар конгрессының матбугат хезмәте.

«Бердәмлек»не саклыйбыз

● «Бердәмлекне»нең беренче санын чыгаручылар.

Самара өлкәсе татар газетасының беренче баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллинга сентябрь аенда 80 яшь тулган булыр иде.

Рәфгать Нәбиулла улы Әһлиуллин – 28 ел буе Самара өлкәсенең милли матбугат кырында үз халкына хезмәт иткән милләтпәрвәр һәм журналист.

Каеннарның яшел күлмәкләре саргылт төскә керә башлаган зыңгылдап торган алтын көз башында туган Рәфгать Әһлиуллинның гомере, шулай ук көзен, күк йөзен кара болытлар каплаган елак һәм караңгы иртәдә өзелде.

Ул китәсен алдан белде. Бәлки газета укучылары хәтерлидер, 75 еллык юбилее алдыннан «Бердәмлек»тә дә, башка өлкә газеталарында да аның турында күп мәкаләләр басылып чыккан иде. Мин, ул вакытта газетаның корреспондентлар бүлеге мөдире булып эшләгән кеше, редакторыбыз турында язылган чираттагы мәкалә газета папкасына яткач, түзмәдем, кабинетына атылып кердем: «Рәфгать Нәбиуллович, кешеләрдән яхшы түгел бит инде, гел-гел сезнең турыда гына язып торабыз!» – дип башлаган идем, сагыш тулы авыр карашын күреп, абынган кешедәй, ярты сүземне дә әйтеп бетерә алмадым. «Бәлки, бу минем соңгы җырымдыр», – диде ул, аска карап.

Кабинет ишеген әкрен генә ябып чыктым да бу теманы башкача кузгатмадым. Ике атна үтте микән, ашыгыч ярдәм машинасы аны кардиология үзәгенә алып китте. Соңгы сүзе шул булды: «Бердәмлек»не саклагыз!..» Сизенгән бит ул, сизенгән! Эх, кирегә әйләндереп булса иде вакыт тәгәрмәчен, бу үкенечле сүзләрне әйтмәгән булыр идем!

Әкүпме яхшылыклар эшләде бит ул халыкка! Хәтерлим, 1992-1993 еллар булгандыр, Урта Азиядән бер татар кешесе кайтып, бирелә урнашып булырмы икән, читтә яшәр хәлебез калмады, куалар, дип зар елады. Кабинетта нәрсә сөйләшкәннәрен ишетмәдем, редакция машинасына утырып кайдадыр барганнарын хәтерлим, өлкә хакимиятенә булса кирәк, анда эш барып чыкмады бугай, кайткач, татар зыялыларына шалтыратып, бу кешегә ярдәм итүләрен сорагалы истә калган. Шулай берничә көн йөрде алар. Әикенче атна башында бу кеше кинәт югалды. Соңрак билгеле булганча, бу мәшәкатьләргә олы яшьтәге абзый түзмәгән, инфаркттан вафат булган...

Рәфгать Нәбиуллович, абзыйның гәүдәсен гаиләсе яшәгән якларга озату мәшәкатьләрен үз өстенә алып, Республика хөкүмәте белән элемтәгә керде. Тимер юл вокзалына барып, юлын табып, халык сәдакасыннан җыелган акчабызны түләп, поездга урнаштырып җибәргәне истә. Бер белмәгән кеше бит инде... Икенче берәү булса, кул гына селтәгән булыр иде. Башлаган эшен ахырына җиткерүчеләрдән иде редакторыбыз. Журналист һәм җитәкче, илдәге сәясәтне аңлап, халыкның бу турыда нәрсә уйлаганын шәйләп, барысын да анализлап эш итә белергә тиеш. Рәфгать Нәбиулловичның бу адымы нәкъ шундый сыйфатлары турында сөйли.

Шул ук чорда ул татар зыялысы, шагыйрь һәм журналист, ләкин инде олыгайган һәм ялгыз яшәүче Фаикъ Давыдовның язмышында да зур роль уйнаганын хәтерлим. Аның рус телендә язылган мәкаләләрен, шигырьләрен тәрҗемә итеп, газетада бастырып, гонорар түләп булса да, авыр матди хәлдән чыгару юлын эзләде. Авырганда, табиблар чакыртып, хастаханәгә урнаштырып йөргән чаклары да булды. Әвафат булгач, гомере буе рус газеталарында эшләгән кешене җирләү мәшәкатьләреннән дә читтә калмады. Рәфгать Нәбиуллович үзе вафат булган көнне, зиратка барып, Фаикъ Давыдовның каберенә истәлек ташы кую эшләрен оештырырга җыена иде. Бу эшен инде безгә, Шамил Галимовка һәм миңа, тәмамларга туры килде.

Гакыйль Сәгыйровның иҗатын популярлаштыру, аның турында китап язып, бастырып чыгару, музей-йортын булдыру эшләре буенча да Кошки районы белән Самара арасын иңләп йөргәнен, шагыйрь Рөстәм Мингалимнең иҗатын популярлаштыру өчен иҗат кичәсе оештырганын, дүрт томлы китабы басылып чыккач, редакция акчасына тиражның шактый өлешен сатып алып, китапханәләргә, мәктәпләргә, аны белгән кешеләргә тараткан күпләр белмидер әле. Безнең гаиләдәдә ул дүрттомлы китап бар, чөнки әнием Сәхия Шәвәлиева Рөстәм Мингалимнең укытучысы иде.

Исебез китә иде инде бу кешегә – исән бер әгъзасы да юк, ә ул, үз-үзен саклау урынына, икейөзле кешеләргә хакыйкатьне ярып салырга да кыенсынмый, көн кадагына язылган кискен язмалары белән тын кул өстеннән дулкын йөгертеп алырга да куркып тормый иде…

Әинде бәйрәм яисә кунак-фәлән килеп чыкса, Рәфгать абый киң күңелле хуҗага әверелә. Кызлар өстәл корып җибәрә, мәрхүм Идеал Муса улы Галәветдинов гармунын күтәреп килеп җитә дә, кичкә кадәр милли матбугат, мәгариф, мәдәният турында сөйләшүләр тынмый, Халыклар дуслыгы йорты коридорлары буйлап татар җыры агыла иде...

Журналистлар берлегенең Самара бүлеге оештырган чараларда катнашкан вакытларыбыз үзенә бер бәйрәм була иде. ГТО нормаларын үтәдек, спорт уеннарында катнаштык, Матбугат көннәрендә, өлкәдә милли матбугат булуын раслау өчен, татар уеннары, концертлар оештыра идек, Сабан туйларының барысын да күрдек, яздык, геройларын мактадык, кайсын ачуланып та алдык. Бүреләр урман санитарлары булса, газета, җәмгыять санитары буларак, булдыксыз җитәкчеләр, ваемсыз хезмәткәрләр белән көрәшү ысулы. Моңа да безне беренче редакторыбыз өйрәтте.

Улкадәр киң атлап булмаса да, Рәфгать Нәбиуллович күрсәткән юлдан бүген дә барабыз. Шундый юбилей көннәрендә, тавык та чүпләп бетермәслек көндәлек эшебездән аерылып, үткәннәргә борылып карыйбыз да утыз өч ел гомеребез юкка үтмәгән, дигән нәтиҗәгә киләбез.

Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле беренче редакторыбыз. Урыныгыз җәннәттә булсын. Әбезнең бу дөньяда эшебез күп әле, без «Бердәмлек»не саклыйбыз!

Эльмира ШӘВӘЛИЕВА.
«Бердәмлек» газетасы,
Самара.

Сарман – зур тарихлы, җырлы-моңлы, талантларга бай төбәк. Ул татар милләтенә күп кенә шагыйрьләр, язучылар, журналистлар, тәрҗемәчеләр, мөхәррирләр, җырчылар, җәмәгать эшлеклеләре һәм артистлар үстереп биргән. Дамир абый Гарифуллин исә, Сарман авылында яшәп, академик дәрәҗәсенә күтәрелде.

Сарман галиме

Фәрит Яхин үзенең истәлекләрендә: «Дамир абый безне колач җәеп каршы алды, риваять мәгарәсе ачкычын да күз уңыннан читкә куйган җиренннән чыгарып, борынгы китаплар тезелгән киштәләр белән тулы бүлмәсенең ишеген ачып җибәрде», – дип яза. Димәк, китаплар – төп ярдәмчеләр икән.

Әтисе Хәйрулла агай һәм әнисе Мәхтүмә апа да китап кадерен белгән. Әтисе борынгы китаплар җыю белән шөгыльләнгән. Әнисе ягыннан Кәлимулла бабасы да укымышлы булган, китаплар күчереп язган, хәттат булган. Китапка тартылу нәселдән килә икән. Үзлегеннән укып, тырышып тарих язучы Дамир абыйның сүзләре үзенә дә туры килә:

Бөтенесе соңгы исәптә
Килә булыр нәсел-нәсәптән.

Дамир абый да бик күп еллар буе борынгы китаплар җыйды. Шуны белгәнлектән, мин аннан Биектау районы Казаклар авылында укучыларым ярдәме белән тупланган шундый китапларны барып алуын үтендем. Дамир абый сүземне тыңлаган, китапларны Сарманга үзенең шәхси китапханәсенә алып кайткан.

Университетның журналистика бүлегендә уку Дамир Гарифуллинны чын журналист итә. Ул «Социалистик Татарстан» газетасының Зәй-Әлмәт төбәгендәге үз хәбәрчесе булып эшли. «Сарман» газетасы мөхәррире вазыйфасын да башкарып ала. Республика газета-журналларында тирән эчтәлекле йөзләрчә мәкалә бастыра.

Дамир абыйның беренче китаплары балаларга багышлана. Бер-бер артлы «Тылсымлы шакмаклар», «Кикринур», «Бакакак», «Ишегалды» дигән китаплары дөнья күрә. Үзе СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алына. Нәниләр өчен язылган шигырьләре һәм җырлары мәктәп дәреслекләренә, дәрестән тыш уку әсбапларына кертелә. Шагыйрь балаларны матур шигырьләре белән шатландыра.

Дамир Гарифуллин – җырлар авторы да. «Чыгарсыңмы каршы алырга?» китабына 56 җыры кергән. Аларны Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шәрифуллина һ.б. җырчылар башкара. Шагыйрь һәр авылның үз җыры булырга тиеш дип саный.

Дамир абыйның бер китабы тоташ робагыйлардан гына тора. Ул үз фикерләрен куен дәфтәренә язып барган, шулардан шигырь юллары туган.

Адым саен берәү кыла этлеген,
Кия үзе әдәплелек битлеген.
Тик белегез: матур чәчәк атса да,
Чүп үләне яшерәлмый чүплеген.

Шагыйрь төрле жанрларда уңышлы эшли. Ләкин ул моның белән генә чикләнми, һаман «энә белән кое казуын» дәвам итә. Ниһаять, «Сарман энциклопедиясе»н ике китап итеп бастыра. Үзе бу хакта тыйнак бәян итә:

– Бу эшкә мине Альберт Фәтхи этәрде. Ул университетның Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәсендә эшли иде. «Әбүгалисина мәгарәсе» дип йөртелгән кульъязмалар һәм сирәк китаплар саклана торган бүлектә. Ул үзе дә «аяклы тере энциклопедия» булып тоела иде миңа.

Әйе, А.Фәтхи Дамир абыйга татар әдипләренең һәм галимнәренең төрле елларда үзе бастырып чыгарган кульъязма мирасына багышланган тасвирламаларын автограф белән бүләк итә торган була. Дамир абыйның мәгарәсенә яңа китаплар өстәлә.

– Мин шактый гомеремне милләтебезнең күренекле шәхесләрен өйрәнүгә багышладым. Күп еллардан бирле китаплар, борынгы кульъязмалар җыю белән шөгыльләнәм, бу өлкәдә гыйльми тикшеренүчеләр белән тыгыз элемтәдә яшим, – ди авыл җирендә яшәгән галим.

Якташ язучыбыз – шәҗәрәләр төзү остасы да. Бикчура хан нәселеннән чыккан кешеләр арасында Сарман карт, галим Ризаэддин Фәхреддин (әнисе ягыннан), язучы Аяз Гыйләҗев, журналист Рафис Могыйнов, табиб Әдип Ибраһимов (Җәлил бистәсендә яши), җырчы Бәширә Насыйрова, язучы Шамил Бикчурин (фамилиясе үк әйтеп тора), артистка Фәридә Сафина, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова бар.

«Шәҗәрәләр»нең беренче китабында 31 шәҗәрәнең нәсел агачы бирелгән. Габдулла Тукай, Муса Җәлил шәҗәрәләрен дә Дамир абый төзегән.

Мортаза Туктулы – Шәмсетдин – Мөхәммәтгалим имам – Мөхәммәтгариф – Габдуллаҗан Тукай.

Кадыйр – Чура – Әбҗәлил – Әбүбәкер – Мостафа – Муса Җәлил...

Тарихчы Дамир Гарифуллин энциклопедик белемгә ия. Ул рухы белән – Ризаэддин Фәхреддиннәр токымыннан. Аңа Аяз Гыйләҗев: «Ярый әле, бу пәрдәсе ачылып килгән дөньяда син бар, тарихны йөгәнләрлек зиһенең бар», – дип язган. Каләмдәшләре аны «шигъри дөнья тылсымчысы», «тарихыбызны җырга салучы», «май ае шагыйре», «язучы академик» дип атады. Татарстан язучылары: «Син – халкыбызның мең еллык әдәбияты һәм мәдәниятен барлаучы, туплаучы, аны милләтебезгә кайтарып бирүче», – ди.

Дамир абый «дөнья мәшәкатен читкә куеп, алтын вакытын һич тә кызганмыйча», гомерен иҗатка, эзләнүгә багышлаган. Бер минут вакытын да бушка уздырмаган. Авыл җирендә яшәп, калын-калын китаплар бастырган. 2002 елда Россия Гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы дигән исемгә лаек булган.

Дамир Гарифуллиннар нәселеннән Мөнәвәрә апа да – китапка мөкиббән кеше. Ул да, Дамир абый кебек, Сарман районының Яхшыбай авылында туган. Әтисе Кәлимулла китаплар күчереп язучы булган. Аларда гарәп хәрефләре белән язылган китаплар дәрәҗәле саналган. Мөнәвәрә апа үзе эшләгән Җәлил бистәсе китапханәсенең уку залында «Туган тел» бүлмәсе ача. Гарәп имлясын өйрәтүчене табып, шунда түгәрәкнең эшен җанландырып җибәрә. Бистәдә халык бәйрәмнәрен үткәрүдә башлап йөри. «Җомга көн, кич белән»не халык аеруча ярата. Ул, Казаннан татар язучыларының яңа чыккан китапларын алып кайтып, сату оештыра. Мөнәвәрә апа Кәлимуллина «Туган як» музеен баетуда тырышлык күрсәтә. Җәлиллеләрне «Сәйдәш аланы»на, Чаллыга, Казанга, Кырлайга сәяхәтләргә алып бара. Транспорт белән «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару оешмасы ярдәм итә. Музейда «Туган тел» клубы эшләп киткәч, бистәдә мәдәни тормыш «кайный» башлый. Җырчылар, шагыйрьләр бер тирәгәрәк туплана. Кыскасы, ул чакларны халык әле дә сагынып искә ала.

Дамир абыйда да, Мөнәвәрә апа да – милли җанлы, сокланырлык кешеләр. Аларның Сарман районы һәм Җәлил бистәсе буенча башкарган изге гамәлләре онытылмас.

Рухия АХУНҖАНОВА.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәваланучы керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

4 ноябрь (шимбә). ***Рабигүл ахир аеның 20 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 21.29 сәгатьтә калка, 14.49 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.04 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Кычыткан (1)

Кычыткан халык медицинасында борын-борыннан кулланыла. Ул C, B, K витаминнарына, каротинга, органик кислоталарга бай. Үсемлектәге хлорофилл матдәләр алмашын көчәйтә, тынычландыра, йөрәк-кан тамырлары системасы, эчәклек, сулыш үзәгенең тонусын күтәрә, зарарланган тукымаларны торгыза. Кычыткан препаратлары кызыл кан тәнчекләренең санын арттыра, кан составын яхшырта, андагы шикәр микъдарын киметә, эчәклекнең лайлалы тышчасын ныгыта. Кычыткан атеросклероз, холецистит, гастрит, ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәтен дәвалый, эренле яраларны җыя. Тәнәтмә әзерләү өчен 1 аш кашыгы кычыткан яфрагын 1 стакан кайнар суда 15 минут төнәтәләр. Дәвалану максатында көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, чирегешәр стакан эчәләр.

5 ноябрь (якшәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 21 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 22.49 сәгатьтә калка, 15.03 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.00 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Ижат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Кычыткан (2)

Биттәге бетчәләрне бетерү өчен, лосьон ясыйлар: 2-3 аш кашыгы вакланган яфракны 1 литр суда кайнатып чыгаралар да, 30 минут төнәткәч, сөзәләр. Көненә 5 тапкыр шуның белән битне юып, сөртмичә киптерәләр. Чәчне үстерү өчен, 3 аш кашыгы вакланган яфракны 1 литр кайнар суда төнәтәләр дә, сөзеп, ай буена чәчне шуның белән чайкыйлар. Чәч агарганда, кычыткан согы сөртү булыша. Аяк табанындагы ярыкларны бетерү өчен, аякны 10-15 минутка кычытканлы суга тыгып утыралар, аннары тукландыргыч крем белән массаж ясыйлар. Игътибар! Каны артык тиз оючан кешеләргә, төрле шешләр булганда, кан акканда кычыткан белән дәвалану тыела.

6 ноябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Кыз йолдызлыгында, 0.08 сәгатьтә калка,15.15 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.56 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Ижат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

7 ноябрь (сишәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 23 нче көне.24 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 1.25 сәгатьтә калка, 15.21 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.52 сәгать.***

(*Дәвамы 18 нче биттә*).

Айга карап карама

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Нарат шифасы

Матдәләр алмашын яхшырту, организмны шлаклардан чистарту өчен, нарат ылысын җыеп, шуның өчтән бер стаканын 1 литр суда 10 минут пешерәләр дә, җылы урында 1 тәүлек тоныдыралар, анннары сөзеп, көн буена су урынына эчәләр.

8 ноябрь (чәршәмбе). ***Рабигул ахир аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 2.41 сәгатьтә калка, 16.13 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.48 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

9 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул ахир аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 15.30 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.44 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Дәва – аяк астында

Күпләр аяк сөякләренең бүлтәеп чыгуыннан зарлана. Дәва исә бик гади: бака яфрагы яки әрекмән яфрагын шушы чыгып торган сөяккә ябып, төнгелеккә җылы яулык белән урап куярга гына кирәк. Тузганак чәчәкләрен ваклап, бераз гына йод кушып, тәнәтү һәм авырткан урынга куеп бәйләү дә булыша.

10 ноябрь (җомга). ***Рабигул ахир аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 3.57 сәгатьтә калка, 15.35 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.40 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Солы кесәле

Мондый кесәл йөрәк, эчәклек, ашказаны өчен файдалы, канны һәм бавырны да чистарта. 2 стакан солы онына (ярманы кәһвәтарткычта яки иттарткычта вакларга була) 1,5 литр су, арыш икмәге катысы яки 1 стакан кефир кушалар да, 1-2 көн әчеткәч, сөзәләр. Гел болгатып торып, куерганчы пешерәләр, тәменчә тоз һәм шикәр өстиләр. Яки ярты килограмм солы ярмасын 2 литр җылы суга салып, 1 стакан кефир өстиләр дә, тәүлек буе тонәткәч, марля аша сөзеп, куерганчы пешерәләр. Сөт яки каймак белән ашыйлар. Ә калган түпкә 2 йомырка, серкә белән сүндерелгән 1 чәй кашыгы сода, 100 грамм атланмай, шикәр, ванилин, кокос вагы һәм он кушып, камыр басалар һәм газ мичендә печенье пешереп алалар.

Мөслимнең шанлы аты бар, Зөлфәте, Фоаты бар

Октябрь уртасында Мөслим районында татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып үтте. Анда Илсөяр Иксанова, Шәмсия Җиһангирова, Роза Хәбибуллина, Зиннур Мансуров, Рафис Корбан, Данил Салихов, Газинур Морат, Факил Сафин, Лилия Гыйбадуллина, Хәбир Ибраһим кебек егермедән артык әдип катнашты.

Бу көннәр әдәбиятыбызны, әдипләрне зурлауның күркәм үрнәгә булды. Мөслимнең бәрәкәтле туфрагында байтак әдип туып үскән. Район үзәгендә, Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбенә алып бара торган юлда Тукай премиясе алган лауреатларның – замандаш мөслимлеләрдән Зөлфәт, Фоат Садриев, Факил Сафин, Ләбиб Леронның портретлары куелган сквер булдырганнар.

Әдәбият көннәре Бүләк авылында шагыйрь һәм мөхәррир Наис Гамбәрнең туган йортында истәлек тактасы ачу белән башланды. Тантанага шагыйрьнең апасы Фәимә белән сеңлесе Фәндия кайткан. Авылдашлары, туганнары язучылар белән бергәләп шагыйрь каберенә чәчәк салуда катнашты. Әдипнең кабер ташына уелып язылган шигъри юллар тетрәндерә:

Мин... туган туфрагымда,
Гомеремнең сыңар яфрагын да
Бирмәс идем көмеш-алтынга...

Туган туфракка дөнья поэзиясе антологиясенә кертерлек шигъри мәдхия бит бу!

Бүләк – ватаныбызга Советлар Союзы Каһарманы Илдар Маннановны биргән авыл буларак та яхшы мәгълүм. Кунаклар авылның уртасына куелган аның бюстына да чәчәкләр салды.

– Заманында шактый зур булган Бүләктә бүген 20 йортта 28 кеше яши, – дип таныштырды Үрәзмәт авыл җирлеге башлыгы Әлфир Закирҗанов авылның бүгенге хәле белән. Авыллар белән бергә милли йөз югала, халык населениегә әверелә бара, шунысы бик кызганыч...

Икенче тукталышыбыз Түреш авылы кырыендагы «Харрас Әюпов чишмәсе». Ә авыл зиратында, шагыйрьнең кабер ташында шигъри васыять:

Дөньяларын мин дә яраттым ла,
Яраттым ла азга булса да –
Яратканнар – кала...
И җир йөзе!
Миннән соң да назга сусама...

Бу юлларда галәми сагыш, тормышны өзелеп ярату, гомернең фани икәнлегенә үкенеч ярылып ята.

Төп чараларның берсе Октябрь (Теләнче) авылында планлаштырылган. Әүвәл биредә гомер кичкән мәгърифәтче, язучы Зариф Мөэминовның 130 еллыгына, аннары район үзәгендә язучы-прозаик, журналист Флүс Латыйфиның 80 еллыгына багышланган кичәләр булды. Зариф аганың «Мажара» романы күңелемә аеруча якын. Мөслим районының Мәллətамак авылында гомер кичергән бабам Әмирҗан Юнысов та, Зариф ага кебек, 1916-1918 елларда Австриядә әсирлектә булган. Ике мәртәбә Георгий тәресе ордены белән бүләкләнгән, унтер-офицер дәрәҗәсен алган. Әмма большевиклар хакимияте урнашкач, әлеге бүләкләрен күкрәгенә тагып йөрү насыйп булмаган шул аңа...

Шагыйрь Марсель Галиев белән Олы Чакмак мәктәбендә шушы авылда туып-үскән Фоат Садриевның музеенда булдык. Укучылар авылдаш әдипнең әсәрләрен яхшы белүләре өстенә Марсель Галиев иҗатын да өйрәнеп, шигырьләрен ятлап куйган. Димәк, мондый сәфәрләр – кунакка килүче язучыларның иҗаты белән кызыксынуга бер сәбәп тә әле. Бу көннәрдә Күбәк, Татар Бүләре, Туйгилде, Әмәкәй авылы мәктәпләре дә, район үзәгендәге лицей, гимназия һәм Тукай исемендәге мәктәп тә кунаклар кабул итте, аларның иҗаты белән таныштырды, үзләрен кызыксындырган сорауларын бирде.

Сер түгел: кайсы гына әдип китапханәгә кермәсен, ул монда минем китапларым бармы икән, дип кызыксына башлый. Моның башка ягы да бар. Бервакыт миңа Оренбург өлкәсенең бер авылында ачып та каралмаган Мөхәммәт Мәһдиев томнарын күрергә туры килде. Шул ук вакытта өлкәнең Әсәкәй авылында яшәүче Әмир Сөләймановтан Мөхәммәт ага әсәрләрен аеруча яратып укуын, тик аларны кулга төшерү ансат булмавын ишеттем. Димәк, Татарстаннан читтәге төбәкләрдә үзара яхшы бәйләнеш, китап алмашу оештырылса яхшырак икән ләбаса.

Рәшит МИНҺАҖ.

Ашытбашта Ибраһим Гази кичәсе

Ашытбаш мәдәният йортында «Милли мәдәният саекмас чишмә» иҗади бәйге кысаларында Ашытбаш һәм Акчишмә авыл китапханәчеләренең иҗат бәйгесе узды. Язучы Ибраһим Гази иҗаты буенча «Онытылмас еллар кайтавазы» исемле чара залда утыручы китап яратучыларны битараф калдырмады. Китапханәчеләр электрон презентация ярдәмендә язучының кыскача биографиясе, иҗаты белән таныштырды. И. Газинең әсәрләреннән өзекләр укылды, «Алмагачлар чәчәк ата» исемле повесте буенча эшләнгән буктрейлер экраннар аша тамашачыларга тәкъдим ителде. Залда утыручы китап укучылар белән «Онытылмас еллар» трилогиясе буенча фикер алышулар булып узды. Шулай ук быелгы җәй өчен актуаль булган «Яңгыр сорау» фольклор күренеше тамашачылар күңеленә хуш килде. Г.Тукай исемендәге Ашытбаш урта мәктәбенең 3 нче класс укучылары күрсәткән бу йоланы бик яратып кабул иттеләр. Әлеге чара яшьләрнең дәртле биюе, матур җырлар, тальян моңнары белән чиратлашып барды. Язучы үзе күптән вафат булса да, ул күтәргән актуаль темалар, кешелек, яшәеш фәлсәфәсе, язучының матур теле еллар үткән саен үзкыйммәтен югалтмый, киресенчә, кайтаваз булып яңгырап тора, үз укучысына барып ирешә.

Талия САБИТОВА,
Арча районы Ашытбаш авылы китапханәсе мөдире.

Җәлил көрәштәше Ян Габдуллин

БАССРдагы Кандра районы башкарма комитетының элеккеге рәисе Муллаян Тимеркәй улы Габдуллин 1943 елда фашистлар әсирлегеннән кача, совет хәрби әсирләре лагерьларында яшерен төркемнәр эшләве турында беренче язма хәбәр калдыра, 1944 елның мартында фронтта һәлак була.

1943 елның 19 сентябрендә Чернигов өлкәсенең Прилуки шәһәре янында фронт сызыгы аша совет солдатлары ягына бер әсир чыга. Йончыган, ябыккан, каралып беткән йөзен сакал-мыек баскан, аягында көчкә басып торган бу кеше үзен совет офицеры Ян Габдуллин – татар әсирләре яшерен оешмасының махсус җибәрелгән хәбәрчесе, дип белдерә. Аны ашаталар, юыну, ял итү мөмкинлеге бирәләр. Аннары ул шушы оешма турында ВКП (б) Үзәк Комитетына донесение язып бирә. «Әгәр Үзәк Комитет бүгенгәчә яшерен оешма эшләве турында хәбәрдар түгел икән, – дип яза ул, – мин, шушы оешманың әсирлектән котыла алган беренче әгъзасы буларак, сезгә шушы хакта белдерүне үземнең партия бурычым дип саныйм».

Аннары ул совет хәрби әсирләренең яшерен төркемнәре Литва һәм Көнчыгыш Пруссия чигендәге Кальвария, Седльце һәм Демблин лагерьларында эшләве хакында бәян итә. Аларның соңгы икесе Польшада урнашкан. Нәкъ менә шунда күпмедер вакыт Муса Җәлил, Гайнан Кормаш һәм аларның якын дуслары җәфа чиккән.

Хатны Үзәк Комитетка җибәргәнче, Габдуллинны гаскәри частьның махсус бүлегендә озаклап тикшерәләр, аның биографиясендәге һәм яшерен эшчәнлегендәге һәр нәрсәне энә күзеннән үткәрәләр. Язганнарның барысы да дөреслеккә туры килүенә инангач кына хатны тиешле урынга юллыйлар. Җавап көтү озакка сузыла. Габдуллин исә сугышка омтыла, әсирлектә коточкыч җәфа чиккәне өчен фашистлардан үч алырга тели. Ниһаять, Габдуллинга хәрби батальон белән командалык итүне ышанып тапшыралар. Күпмедер вакыттан соң Мәскәүдән, Үзәк Комитеттан аңа чакыру кәгазе килә. Күрәсең, анда Габдуллинның үзе белән сөйләшеп, яшерен оешма турында тулырак мәгълүмат алырга телиләр. Әмма Габдуллин бу вакытта инде сугышта була. Шунысы да комачаулый: аны «Ян» буларак, хәтта, поляк кешесе дип, Польша солдатлары арасыннан эзләтәләр. Чынлыкта исә ул Муллаҗан була. Ниһаять, аның эзенә төшәләр. Әмма Габдуллинның 1944 елның 5 мартында Хмельницкий өлкәсенең Сосновка авылы янындагы каты алышта һәлак булуы ачыклана.

● Муллаҗан Габдуллин.

● Муллаҗан Габдуллин.

● Муллаҗан Габдуллинның хатыны Әсма һәм өч улы.

Җәлилчеләрдән берсе Муллаҗан Тимеркәй улы Габдуллин 1906 елда Туймазы районының Яңа Арсланбәк авылында туган. 1925 елда Бәләбәй педагогика техникумын тәмамлый. Башта – укытучы, соңыннан мәгариф бүлеге мөдире булып эшли. 1933-1937 елларда армиядә хезмәт итә. Лейтенант булып кайткан егетне җитәкчелек эшенә алалар. 1939 елдан ул Кандра районы башкарма комитеты рәисе булып эшли, халык арасында абруй казана. Сугыш башлангач, үз теләге белән фронтка китә. Волхов фронтында дошман тылына десант булып төшкәндә каты яраланып, немецлар кулына эләгә. Башкортстанда балалары белән хатыны Әсма Афзал кызы кала. Алар аның язмышы турында озак еллар буе берни дә белми. 1944 елның апрелендә генә Габдуллинның фронтта батырларча һәлак булуы турында хәбәр килә.

Муллаҗан Тимеркәй улының килене Асия Габдуллина әйтүенчә, Әсма ирен гомере буе сагынып яши. 1947 елда ул өч улы белән Башкортстаннан Үзбәкстанга күченә. 40 ел буе башлангыч сыйныфларны укыта. Сугышка кадәр үк Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән була, аны Мәскәүдә М.Калинин үзе тапшыра. Олы уллары педагог һөнәрен сайлый, уртанчысы инженер-энергетик була, кечесе, Риф, нефть техникумын тәмамлый, 1975 елда гаиләсе һәм энисе белән Болгарга күченеп кайта һәм озак еллар буе «Татмелиоводстрой» оешмасында тракторчы булып эшли.

«1976 елның апрелендә мин Рафаэль Мостафинның «По следам поэта-героя» дигән китабын сатып алдым, – дип хатирәләрен барлый Рифнең хатыны Асия Кадыйр кызы. – Каенанама күрсәттем. Ул Муса Җәлилнең көрәштәшләренә кагылган бөтен нәрсәне укып бара, язучы Исхак Зәбиров белән таныш иде. Бу юлы да игътибар белән укып чыкты, бигрәк тә ире Муллаҗан Тимеркәй улы турында язылган җирләрне. Аннары бик дулкынланды, борчылды».

Шул ук көнне олы улыннан да хат килеп төшә. Ул Хмельницкий өлкәсендә әтисенең каберендә булуы турында яза. Әсма ханым улы әтисе кабереннән бер уч туфрак алып кайтканмы-юкмы икән дип тә хафалана. Алып кайткан була, тик Әсма Афзал кызы бу хакта белми кала инде.

«Соңгы вакыйгалар аны шулкадәр тетрәндерде ки, каенанамның йөрәге түзмәде, һәм ул бер атнадан соң 67 яшендә кинәт вафат булды», – дип искә ала Асия Габдуллина. Ул үзе балалары һәм оныклары белән Болгарда яши.

Карина КОСТРУЛЕВА.
«Казанские ведомости».
https://kazved.ru/news/on-rvalsya-v-boi-zizn-i-sudba-odnogo-iz-soratnikov-dzalilya-5849414

Биг Бен ...манара түгел

Туристлардан “Биг Бен манарасы” дигәнне ишеткәч, хәзер Лондонда яшәүчеләрнең ачуы да чыкмый инде, күнеккәннәр, әлегрәк исә бу гыйбарә аларның колагын ярып керә торган булган. Чынлыкта исә Биг Бен – Вестминстер аббатлыгындагы сәгатьле манарадагы алты чаңның иң зурысы ул, авырлыгы 13,7 тонна тәшкил итә. Аны 1859 елның 31 маенда (сәгатьне эшләтеп җибәргән көнне) шулай атаганнар. Атаманы парламент сайлаган. Кушаматы “Биг Бен”– “Зур Бен” булган урман хуҗалыгы кураторы Бенджамин Холл әлеге утырышта барысыннан да катырак кычкырып утырган. Аның чираттагы, бигрәк тә ахмак бер репликасыннан соң залдан берәү: “Әйдәгез инде, чаңны Зур Бен дип атыйк та, таралышыйк!” – дип кычкырган. Зал шаркылдап көлә башлаган, тик шулай да кушамат тагылып калган. Чаң эленгән манара исә Сен Стивен дип аталган, 2012 елдан исә, королеваның 60 ел буе хакимлек итүе хөрмәтенә, рәсми рәвештә Елизавета манарасы, дип йөртелә, аның биеклеге 96 метрга тәңгәл.

(“The Local”).

Ә Җир барыбер әйләнә!

Без әлеге гыйбарәне Галилей әйткән һәм аны шуның өчен яндырганнар, дип беләбез. Тик бу болай түгел икән. XVI гасырда яшәгән астроном Николай Коперник күкне күзәтергә яраткан һәм Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүенә беренче булып төшенгән, тик бу турыда кычкырып йөрмәгән, үзенең формулалары янына язып куйган да, 70 яшендә тыныч кына бакыйлыкка күчкән. Ә менә шагыйрь Джордано Бруно Коперник хезмәтләреннән Җирнең Галәмдәге кечкенә планеталардан нибары берсе булуын гына хәтеренә сеңдергән һәм шуңа үзенең дини тәгълиматын нигезләгән. 1584 елда шәһәрләр буйлап вәгазь сөйләп йөри башлаган, 16 елдан соң аны еретиклыкта гаепләп яндырганнар. Галилео Галилей исә зур галим булган, Айдагы тауларны һәм Кояштагы тапларны ачкан. 1632 елда, Коперникның тәгълиматын тәфсилләп аңлатып, китап язган, бер елдан соң үзен судка чакырганнар. Анда ул үзенең хаксызлыгын танығач, төрмәгә дә утыртмыйча, өенә кайтарып җибәргәннәр. Карт галим “Ә Җир барыбер әйләнә!” дип әйтмәгән шул, алайса үзенең Флоренциядәге вилласына исән-имин кайтмас иде. Гыйбарәне исә XVII гасырда Галилей портретына аның шәкертләреннән берсе язып куйган, әлеге буталчыклык шуннан килеп чыккан.

(“AdMe.ru”).

Чама белү кирәк

АКШтагы Джорджтаун университеты медицина үзәге тикшеренүчеләре, 40-65 яшьлек 76 мең хатын-кызның сәламәтлеген күзәтеп, төрле ризыкларның буыннарга тәэсирен өйрәнгән. Сынау җитәкчесе профессор Кристофер Коллинз әйтүенчә, әлегәчә иң файдалы эчемлек, иң куәтле антиоксидантлардан саналган кара чәйне көненә 4 чынаяктан күбрәк куллану хатын-кызларда ревматоидлы артрит башлану ихтималын күпкә арттыра. Әмма профессор кара чәйдән баш тартырга өндәми, чөнки анда файдалы матдәләр дә бик күп. Шунлыктан иң яхшысы – кара чәйне көненә 1-2 чынаяк эчеп, калган вакытта яшел чәй белән сыйлану, анысының буыннарга зыяны юк.

(“The Guardian”).

Дүрт гасырлык агач

Вашингтондагы Милли дендрарийда 398 яшьлек бонсай (кәрлә агач) үсә. Ул 1625 елда утыртылган булган. Японияләге Йамаки нәселе гаиләсендә гасырдан-гасырга күчеп үскән. 1945 елда америкалылар атом бомбасы ташлаган Хиросимадан ике миль ераклыкта гына булган. Гаҗәп хәл: 140 мең кешенең гомере өзелгән фаҗигадә бонсай да, Йамакилар гаиләсе дә исән калган.

(“The Washington Post”).

Яшен каныккан кеше

Британиядән майор Уолтер Саммерфолдка исән чагында өч тапкыр, аннары кaберенә тагын бер тапкыр яшен аткан. 1918 елда Фландрия кырларындагы яуда майорны яшен атыннан бәреп төшергән, паралич суккан хәрби Ванкувердагы госпитальдә әкренләп савыккан. 1924 елда, елга ярында балык тотканда, төбендә Уолтер утырган агачка яшен суккан, аның уң ягы параличланган. Ике елдан соң Саммерфолд тулысынча савыккан. 1930 елда, паркта йөргәндә, тагын яшен аткан һәм Уолтерны тагын паралич суккан. Ике елдан соң вафат булган. Тагын дүрт елдан соң исә яшен кaберендәге ташка аткан һәм аны челпәрәмә китергән. Бу җиһанда яшен суккаңнан үлү ихтималы 2 миллионга бер тапкыр тәшкил итә, караваттан егылып үлү ихтималы да шул кадәр. Саммерфолдның никадәр “уңышлы” булуын шуннан үзегез чамалагыз инде...

(“Batona.net”).

● Porsche 356C.

● Гай Ньюмарк.

Тузмый торган машина

Автомобильләрнең күпчелеге 200-300 мең километр ара үткәннән соң инде бик искергәнгә санала. Әмма бу кагыйдәдән чыгарылмалар да бар. Америка Кушма Штатларында Гай Ньюмарк бүген дә 1960 елда чыгарылган машинасында җилдерә. Аның Porsche 356C автомобиле миллион мильдән артыграк (1,6 миллион километр чамасы) юл үткән. Башта әтисе йөргән, аннары колледж тәмамлаган улына бүләк иткән. Машинаны 1971 елдан бирле бер генә механик – Фред Буше гына карап тота, аның янына Гай һәр 3 мең миль ара үткән саен бара. Әлбәттә, 60 ел эчендә кайбер детальләрен яңартырга туры килгән, шулай да Porsche 356C трансмиссиясендә шул вакыттан бирле нибары биш подшипник кына алыштырылган. Гай әйтүенчә, бу машинаны йөртү бик рәхәт, ярты гасыр элек ничек яхшы йөрсә, хәзер дә шулай ук – бернәрсәсе дә дөбердәми дә, шыңгырдамый да. Ул үзенең зәңгәр машинасында көн саен йөри һәм әле варисларына да васыять итеп калдырырга җыена. Канадалы Билл Макичерн исә үзе 1976 елда сатып алган Porsche 911 Turbo машинасын дөньяда иң яхшы автомобиль, дип саный. Шул машинасында көн саен йөреп, ул барлыгы 1 миллион 260 мең километр ара үткән инде, әле киләчәктә дә рәхәтен күрергә өметләнә.

(“Fishki.net”).



● Билл Макичерн һәм аның Porsche 911 Turbo машинасы.

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

6 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
10.00, 17.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «ДЕПАРТАМЕНТ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
14.50 «Халкыбыз мирасы». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
23.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Халкыбыз мирасы». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 16+
9.50 «Семь дней». 16+
